

## Салават Хәбибуллин: «Авыл мичендә бәлеш пешерәсем килә»

«Өйдә бәлеш, өчпочмак, кыстыбый кебек милли ризыкларны ятып пешерәм. Билгеле бер рецепт буенча гына әзерләмим, тагын нидер өстим. Шуларны авыл мичендә дә пешереп карыйсым килә. Пешергән ризыкларымны дусларым мактап ашый. Нәрсә генә эшләсәң дә, аңа җан җылысын салырга кирәк.»

7 БИТ



## Ел укытучысы Илсур Метшинны баерга өйрәтте

Казан Ратушасында «Казан шәһәренең ел укытучысы» бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Анда барлыгы 500дән артык мөгаллим катнашты, ләкин төрле сынаулар аша финалга нибары 95е генә үтә алды.

6 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

# Шәһри КАЗАН

татмедиа

**Җомга** | 3.03.2017 | № 22 (5784)

www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

# ЯЗГА КЕРДЕК

**Урамда шундый рәхәт! Кояш көлә, тамчылар тама, колакны кошлар сайравы иркәли! Кояшның елмаюн күреп, үзебезнең дә кәефләр күтәрелә. Башка елларда апрель башы-урталарында гына эрегән кар катламы быел февраль ахырында ук гөрләвекләр булып ага башлады.**

**Зөһрә САДЫЙКОВА**

Шулай да күңел кыштан арып, язны көтү белән җилкенсә дә, алда безне салкыннар, сыерчык бураннары көтәдер төсле. Россия Гидрометеорология үзәге директоры Роман Вильфанд «Российская газета»га җиткергән фаразлар буенча да, чын яз 23 мартта башланачак икән.

– Һава температурасының тәүлек дәвамында 0дән югарырак күтәрелүен март азагында гына көтәргә кирәк. Мәскәү зонасында, һәрхәлдә, шулай булачак. Елгалар боздан апрель башында ачыла, кара каргалар март азагында кайта. Чын яз 23 мартта башлана, – ди ул.

Шул ук вакытта Россиянең барлык территориясендә дә март җылы булачак икән. Һава температурасының климатик нормадан 4-10 градуска җылырак булуы көтелә. Аерупча үзәк зонада җылы булачак, дип фаразлана. Роман Вильфанд сүзләренчә, Татарстанда һава температурасы нормадан 6-8 градуска җылырак булачак икән. Шулай да ул әле 0дән түбән – 2-4 градус чамасы салкын булачак, ди.

Исегезгә төшерәбез, табигатьне ел дәвамында күзәтеп барып, ел фасылларының ничек киләчәген алдан әйтүче Кукмара районының Рудник авылында яшәүче Фәйзрахман Бариев та бернничә атна элек «Шәһри Казан» газетасына үзенең фаразларын җиткергән иде. Аның февральгә карата булган күзәллаулары, чыннан да, дөрескә чыкты. Бәлки, март та нәкъ менә ул әйткәнчә килер.

– Февральдә кар артык күп ямаячак, көннәр артык суык булмас кебек. Булса да, бернича көн генә суытып алачак. Март аенда, гадәттәгечә, суык булачак. Көннәр 20ләреннән соң гына җылытачак, – дигән иде ул.



livejournal.com/krug51

## Яз килүен сизәсезме?

**Лилия МУЛЛАГАЛИЕВА,** Татарстанның атказанган артисты:

– Шәһәр үзәгендә карлар эреп, сулар акканлыктан, яз килүе сизелсә дә, үзебез яши торган бистәдә әлегә кыш уртасы кебек. Урамда ап-ак кар, Идел өстендә калын боз ята. Шуңа күрә әлегә ишегалдында кар көрәүдән башка мәшәкать юк. Кайвакыт кояшның яктырак балкуы гына тиздән яз җитүен хәбәр итә. Безнең йорт калку урында урнашкан. Казан бездән астарак. Шуңа күрә елга янында яшәвебезгә карамастан, су басу проблемалары безне читләтеп уза.

**Ләбиб ЛЕРОН,** «Безнең мирас» журналы баш мөхәррире, язучы, шагыйрь:

– Туганнарым яшәгән Актаныш, Мөслим районнарында көннәр суыграк әле. Ә Казаныбыз язга ашкына. Күңелдә дә яз бөреләнә, уяна. Мин аның исен Инстаграм, ватсап аша килгән кояш, кар астыннан шытып чыккан умырзая чәчәкләренең рәсемнәре аша тоям. Яз шаукымы тәэсире дер инде, театрларга, концертларга йөрисе килә. Моннан ун еллар элек бакчабызны су баса иде, хәзер андый бәла-казалар белән очрашкан юк анысы. Без кечкенә чакта боз кузгалуын карарга төшә, теләкләр тели идек. Бик көтеп ала торган идек шул вакыйганы. Шуңа күрә бүген дә һәр кешегә куанычлы айлар килүен телим.

**Илкәй КОРБАНОВА,** Биектау районы, Өбрә авылы:

– Әлбәттә! Кошлар сайрый, кояш елмая, күңел күтәренке. Шулар белән бергә авыл җирендә атна саен эшләр дә арта бара. Түбәләрдәге карларны төшерергә, юлларда ерымнар ерырга, кар көртләрен таратырга кирәк.



kazan.mk.ru

# КОТЛАУЛАР КӨНЕ

**Президент Рөстәм Миңнехановны 60 яшьлек юбилее белән гади халыктан алып «Голливуд йолдызлары»на кадәр котлады. Республика җитәкчесенә һәркем ихлас теләкләрен, рәхмәтен җиткерергә ашыкты.**

1 март көнне Министрлар кабинеты каршында иртә таңнан Казан федераль университеты студентлары «Рөстәм Нургалиевич, юбилеегыз белән» дигән зур плакат тотып чыгып баскан иде. Аларның бу урынны сайлавы тиктән түгел. Президент үзе һәркөнне иртәнге 6-7ләр тирәсендә шул мәйданны фотога төшереп, Инстаграмга элә һәм хәерле иртә тели.

Туган көне булуга карамастан, Президентның эш графигы һәрвакыттагыча тыгыз булды. Шулай да ул Instagram челтәрендә юбилей белән котлап ясалган роликларны карарга вакыт тапкан, «Котлауларыгыз өчен рәхмәт!» дип тә язган.

Татарстан халкы Президентка ышана, аны хөрмәт итә. Моны федераль дәрәҗәдә һәм башка илләр җитәкчеләре дә ассызыклыйлар. Россия Президенты Владимир Путин да котлавында: «Югары дәрәҗәдәге профессиональлек һәм хәбәрдарлык, туган якны чын күңелдән ярату өчен Татарстан халкы Сезне хөрмәт итә», – дип искәрткән. Россия хөкүмәте рәисе Дмитрий Медведев Рөстәм Миңнехановны Татарстанда зур хөрмәткә ия кеше дип атаган. «Республика үсеше, аның сәнәгый һәм авыл хуҗалыгы мөмкинлекләрен ныгыту, халыкның тормыш дәрәҗәсен арттыру өчен Сезнең ярдәм белән күп нәрсә эшләнгән. Бүген бирелдә Сезнең тәкъдимегез буенча зур күләмле инвестицион проектлар гамәлгә ашырыла, шул исәптән без бергә ачкан «Иннополис» махсус икътисади зонасы. Шулай ук төбәктә заманча сырхауханәләр, мәктәп һәм балалар бакчалары, торак комплекслары, юллар актив рәвештә төзелә, шәһәрләр һәм авыллар төзекләндерелә. Боларның барысын да татарстанлылар уңай каршы ала, Сез биредә сәләтле оештыручы буларак абруй казандыгыз, Сезне ачык, ярдәмчел һәм игътибарлы кеше дип саныйлар. Алга таба да шундый булып калыгыз», – дигән Дмитрий Медведев. Спорт гимнастикасы буенча дүрт тапкыр олимпия чемпионы Алексей Немов Рөстәм Миңнехановның спортка игътибарлы булуын билгеләп узган «Рөстәм Нургалиевич, Россия чемпионатлары гына түгел, дөнья күләмендә турнирлар уздыруга мөмкинлекләр бирә торган кеше. Казан – мондый ярышлар уздыра белгән лаеклы шәһәр», – дигән.

Котлаулар Президентка көн дәвамында илнең төрле почмакларыннан килгән. Алар арасында Белоруссия Президенты Александр Лукашенко, Кыргызстан Президенты Алмазбәк Атамбаев, Төрекмәнстан Президенты Гурбангулы Бердымөхәммәдов, Казахстан Президенты Нурсолтан Назарбаев, Дәүләт Эрмитажы директоры Михаил Пиотровский, Россия Федераль җыены Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенко, Россия Федераль Җыены Дәүләт Думасы рәисе Вячеслав Володин һәм башкаларның тәбрикләүләре дә бар. Чечня Республикасы башлыгы Рамзан Кадыйров: «Без Рөстәм Миңнехановтан үрнәк алабыз һәм һәркөнне аның эшчәнлеген күзәтәбез. Шуны әйтәсем килә: без һәрвакыт бергә. Тормышның барлык очракларында да», – дигән. Әзәрбайҗан Президенты Илһам Алиев Әзәрбайҗан һәм Татарстан халкы арасындагы күп гасырлык дуслык, үзара хезмәттәшлек һәм ярдәмләшеп яшәү традицияләре саклануда Рөстәм Миңнехановның зур хезмәтен билгеләп үткән.

ЮНЕСКО генераль директоры Ирина Бокова котлавында Бөтендөнья мирасы буенча 2012 елда Казанда узган Яшьләр форумын искә алган. Ул форумны барлык илләрдә яшьләрне толерантлыкка өндәүдә, диннәр төрлелеген аңлап тәрбияләүдә мөһим чара булуын искәрткән. Мәскәү һәм Бөтен Русь Патриархы Кирилл да Татарстанны төрле милләт һәм төрле диндәге халыклар дус, тату яши торган төбәк дип әйтеп узган.

Рөстәм Миңнеханов котлаулар, изге теләкләр өчен ихлас күңелдән рәхмәтен җиткерде. Шулай ук ул Татарстан Президенты посты эшчәнлегендә хезмәтенә бирелгән югары бәя өчен рәхмәт әйтеп, республика иминлеге, чәчәк атуы һәм Россия дәүләтен ныгытуда бөтен көчемне бирәчәкмен, диде.

# Путин Казанны үрнәк итеп китерде

**2019 елда Красноярскида XXIX кышкы Универсиада үтәчәк. Россия Президенты Владимир Путин аңа әзерлек барышы буенча утырыш уздырды. Үзенең чыгышында, дөньякүләм спорт чараларының ил өчен мөһимлеген ассызыклап, Путин Казанны мисал итеп китерде.**

– Спорт чараларына әзерлек барышында яңа объектлар сафка баса, инфраструктура яңартыла, юллар төзелә. Сочида Олимпиада, Казанда Универсиада узды. Шул чор эчендә шәһәрләр матурланды, спорт объектлары гына түгел, транспорт, туристлык, мәдәният, социаль инфраструктура да яңарды. Яңа төзелгән объектлар ярышлардан соң да эшләрме дигән шик бар иде. Казанда да, Сочида да объектлар актив эшли, – диде ул.

Утырыш барышында Президент допинг проблемасына да тукталды.

– Россиянең допингка каршы контроль системасының нәтиҗәле эшләмәвен танырга кирәк. Допинг-контроль өчен җавап бирә торган халыкара оешманың кисәтүләренә колак салырга тиешбез. Допинг куллану фактларын танырга, тикшерү алып барырга һәм гаеплеләргә тиешле җәзаны бирергә кирәк, – диде Путин.

## ТОП-4

**ТАТАРСТАН** 2018 елдан старт алачак пенсия системасын үстерү буенча федераль программада катнашырга теләк белдерде. Татарстаннан Дәүләт Думасы депутаты Ольга Павлова сүзләренчә, быел республика социаль тармактагы халыкны эш белән тәэмин итү һәм мөмкинлек мохите дәүләт программаларына да кертелгән. Финанслану тулы күләмдә федераль үзәктән расланган, шул исәптән федераль үзәктән инвалидларны социаль яклауга биш млрд сум субсидия бирeләчәк.

**ЧИТ** ил кешеләре уллыкка алган ятимнәр саны соңгы өч елда өч тапкырга кимегән. 2016 елда чит илгә 430 баланы уллыкка алдылар, дип белдергән Россия Югары суды башлыгы Вячеслав Лебедев. Ул хөкемдарларның Россиядәге бала алучыларга өстенлек бирүләрен, әмма чит ил гражданнарына уллыкка бирү бала мәнфәгатьләрен күздә тотып эшләнүен билгеләп үткән.

**XVII** Федераль Сабан туе үтәчәк көн тәгаенләнде. Ул 12-13 май көннәрендә Әстерхан шәһәрендә узачак. 2018 елда аны Санкт-Петербург шәһәрендә билгеләп үтәчәкләр. 2020 елда исә чара Татарстан башкаласында оештырылыр дип планлаштырыла.

**ЛДПР**дан Дәүләт Думасы депутаты Иван Сухарев Ватанны саклаучылар көнен августка күчерү тәкъдиме белән чыккан. Бу хакта «Известия» басмасы хәбәр итә. Дәлил итеп, «данлы традицияләр» һәм җылы вакытта өстәмә ял көне булуы китерелә. Сухарев традицияләргә сылтама белән, революциягә кадәр Россия гаскәрләре көне Россиянең Төркия һәм Польша белән сугышы вакытында – 1769 елның 29 августында билгеләнгән булуын әйтә.

## КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстанның Белорецк, Габҗәлил, Бөрйән, Архангельск һәм башка районнарында яшәүче умартачылар «Башкорт балы» дип исемләнгән күмәк бренд буларак берләшергә мөмкин. Бу балны күпләп сату һәм сатып алу өчен эшләнә. Республиканың умартачылык продукциясе җитештерүче һәм эшкәртүчеләре ассоциациясе вице-президенты Сергей Мөлеков фикеренчә, башкорт балының дөнья базарындагы көндәшләре арасында өстенлеге – экологик яктан чиста булуында. Чөнки андагы балның 30 процентка якыны фальсификат. Тик шул ук вакытта умартачыларга бал кортларын карау, тәрбияләүнең заманча ысулларын өйрәтү программасы аз үсеш алган.

Чувашстанда апрельдә кояш батареялары эшләп чыгара башлаячаклар. Завод директорлары советы рәисе Виктор Вексельберг хәбәр иткәнчә, алар бөтенләй яңа төрле панель булачак. Әлеге кояш батареялары экспортка чыгарылачак һәм альтернатив энергетика җитештерүгә киңәйтәчәк. Җитештерү бәясе 40 млн сумга кадәр җиткән.

Мари Элда балаларның җәйге ялына әзерлек башланган. Быел аларны сәламәтләндерү «Журавушки» балигъ булмаган балалар өчен социаль-тернәкләндерү үзәге базасында оештырылган. Бирегә барлыгы 1200 бала килер дип көтелә, шуларның 100дән артыгы – имин булмаган гаиләдә яшәүчеләр һәм 50се – инвалид бала. Җәйге чорда 14 көнлек алты смена оештыру күздә тотыла.

# Президенттан – дәрес

**Туган көне иртәсен Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов Казанның 3нче гимназиясендә экология дәресе бирүдән башлады.**



Дәрес башланганчы, балалар республика җитәкчесен «Мәктәп эко-патруле» программасы һәм «Экошәһәр» проекты белән таныштырды. Рөстәм Миңнеханов исә бу проектларның мөһимлегенә басым ясады.

– Әйләнә-тирә – яшәү сыйфатының аерым бер дәрәҗәсе. Ул тиешле таләпләргә туры килмәсә, медицина да, спорт та сәламәтлекне саклап калырга ярдәм итә алмый. Бу бик мөһим әйбер. Әлеге мәсьәләне балачактан, мәктәп бусагасыннан балага сеңдереп барырга кирәк, – диде ул.

Президент соңгы арада халык арасында шау-шу тудырган Казанда төзелеп килә торган чүп яндыру заводы темасына да тукталып китте.

– Заводны табигатьне пычратучы объект буларак күрсәтәләр. Бу алай түгел. Без, киресенчә, аны барлык калдыкларны бетерү максатыннан төзергә тырышабыз. Россия делегациясе составында Токио шәһәрендә булдык. Анда шәһәр эчендә 21 чүп яндыру заводы эшли, ләкин табигатькә дә, кешеләргә дә бернинди куркыныч тудырмый, – диде Рөстәм Миңнеханов.

**«Метроэлектротранс» башкаланың барлык пассажирларының 27 процентын йөртә, ә халык арасында аеруча популяр һәм уңышлы маршрутлар – 5нче трамвай һәм 1нче троллейбус маршрутлары. Бу хакта «Метроэлектротранс» муниципаль унитар предприятиесе генераль директоры Әсфән Галәвов журналистлар белән очрашу вакытында җиткерде.**

# Киләсе тукталыш – «Иманлек» станциясе

– Узган елны без зур уңышлар белән тәмамладык. Яңалыкларыбыз да күп. Халык арасында аеруча популярлык алган трамвай һәм троллейбус маршрутлары, һәр көн 5,30 минут интервал белән хәрәкәт итә торган тугыз состав эшли. Моңа кадәр үзебезнең контроль системасы иде. Быелдан безне тулысы белән пассажирлар ташу оешмасы контрольдә тота, – диде ул.

Әгәр предприятиенең эшчәнлегенә нәтиҗә ясасак, трамвай юллары, контакт челтәрләрен төзекләндерү буенча да күп эшләр башкарылган. Узган елның тагын бер яңалыгы – трамвай деполары һәм биналарның үзәк җылылык белән тәэмин итү системасыннан баш тартып, җылыту казанына күчү. Нәтиҗәдә, елына бу 22 млн сум акчаны янга калдырырга ярдәм иткән. Җитәкче сүзләренә караганда, әлеге чаралар эшчеләргә яхшы хезмәт хакы түләү мөмкинлеген биргән.

«Метроэлектротранс» предприятиесенең пластик тәрәзәләр, пыялалар эшләп чыгару, тегү цехлары бар, бөтен бүлмәләрдәге ут яктырткычлары светодиодлыларга алыштырылган. Хәрәкәт итү датчигы да электр энергиясен күп кулланмаска ярдәм итә.

Әсфән Галәвов сүзләренә караганда, узган ел 40 троллейбус һәм ун трамвай сатып алынган. Быел исә федераль программа кысаларында, тагын җиде трамвай һәм 15 троллейбус алырга өметләнәләр. Быел Казандагы барлык транспорт өчен 179 млн сум акча бүлеп бирелгән. Сатып алынган трамвай-троллейбуслар саны буенча Казан Мәскәү һәм Петербургтан калышмый. Күчмә состав гел яңартылып тора. Бүген иң иске дигән троллейбус та 2007 елгы икән. Ә һәр троллейбусның хезмәт итү озынлыгы – җиде ел.

– Әмма безнең ун ел йөргән троллейбуслар да өр-яңа кебек әле, – ди Әсфән Галәвов.

Уңышлар, табышлар белән беррәттән, җитәкченең күңелен төшерә торган күренешләр дә бар.

– Соңгы вакытта автомобиль йөртүчеләр гаебе белән аварияләр бик нык артты. Алар бер-берсе белән дә, безнең белән дә күп бәрелешә башлады. Нәтиҗәдә, пассажирлар зарлана, ә без табышны югалтабыз. Дөрес, соңыннан без аны гаепле кешедән кайтартабыз. Әмма эш монда акчада гына түгел бит, пассажирларның вакыты югала. Аннан соң трамвай-троллейбусларны төзекләндерергә туры килә, ә моның өчен күпмедер вакыт кирәк, – дип борчылуын белдерде Әсфән Галәвов.

**«Метроэлектротранс» предприятиесендә эшләүчеләрнең 30 проценты – яшьләр. Уку йортын тәмамлап килүче егет-кызларның окладына 10 процент хезмәт хакы өстәлә. Әгәр ел дәвамында бер тапкыр да юл һәлакәтенә эләкмәсә, өстәмә рәвештә тагын ун мең сум акча бирелә. Моннан тыш, хезмәткәрләр форма белән тәэмин ителә, читтән килүчеләр өчен тулай торак бар, җәй көне шифаханәгә юллама бирәләр. Бүгенге көндә бирердә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы – 28 000 сум.**

Бу елның зур планы ул, әлбәттә, «Иманлек» станциясен җибәрү. Ул 30 августта эшли башлар дип планлаштырыла.

Зөһрә САДЫЙКОВА.

# Юлыма аркылы төшмә!

**Россиядә «Ашыгыч ярдәм» машинасын үткәреп җибәрмәгән очракта җәзаны катгыйландыру турында закон проекты әзерләнгән. Закон кабул ителгән очракта, бу – исерек килеш рульгә утыруга тиңләнәчәк. Әлеге хакта Россия сәламәтлек саклау министры Вероника Скворцова белдерде, дип яза «ТАСС».**

Скворцова сүзләренчә, әлеге закон проекты белән җәзаны катгыйландыру, машина йөртү хокукыннан мәхрүм итү, шулай ук штрафның күләмен зурайту тәкъдим ителә. «Бу чынбарлыкта машина йөртү таныклыгыннан 1-1,5 елга кадәр мәхрүм итүгә китерәчәк», – ди ул.

Сәламәтлек саклау министрлыгы исә штрафның күләмен 30 мең сумга кадәр күтәрергә тәкъдим итә.

– Бу чара бөтенесен дә акылга утыртыр дип өметләнәбез. «Ашыгыч ярдәм» машинасын уздырмау турында күп сөйләнелә. Әмма бу хәзер генә килеп чыккан хәл түгел, – дип тә өстәгән Скворцова.

# Сирена нинди хәбәр ирештерә?

**1 мартта Халыкара Гражданнар оборонасы оешмасына 85 ел тулды. Әлеге зур чара уңаеннан, Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчесе урынбасары Андрей Орлов журналистлар белән очрашты.**

Шунысы да бар: әлеге вакыйга Татарстанда хәбәр итү системасы тикшерелгән көнгә дә туры килде. Шуңа күрә журналистларны кубесенчә Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының менә шушы өлкәдәге эшчәнлеге кызыксындырды.

Андрей Орлов әйтүенчә, халыкка теге яки бу хәбәрне җиткерү системасы 70-80нче елларда урнаштырылган. Алар бүген дә эшли. Дөрес, нинди дә булса куркыныч янаган урыннарга (су басу, янгыннар куркынычы булган территорияләргә) сиреналары өстәмә рәвештә соңгы елларда гына урнаштырганнар. Сиренадан кала, кеше күп җыелган урыннарда (сәүдә үзәкләрендә, спорт объектларында) – махсус экраннар, транспортта – «йөгерек юллар», йөртта яшәүчеләргә домофоннар аша хәбәр ирештерелә. Болардан кала, теге яки бу гадәттән тыш хәлләрне халыкка смс-хәбәр аша да җиткерәләр. Мондый чаралар ярдәмендә яңалык халыкның 70-80 процентына барып ирешә, ди белгечләр.

– Бүген без хәбәр итү системасын планлы рәвештә тикшердек. Тегенди-мондый хәл килеп чыккан очракта, сирена тавышын ишетү белән үк телевизорны кабызып, "Яңа Гасыр" телеканалыннан җиткерелә торган хәбәрне тыңларга кирәк. Беркая да йөгерергә, курkып калырга кирәкми. Аннан соң һәр кеше үзе яши торган йортның подвалына төшәргә тиеш, – диде Андрей Орлов.

Халыкның тормышына куркыныч янаган очраклар килеп чыкканда, саклану корылмаларына, ышыклану урыннарына һәм подвал биналарына яшеренергә кирәк. Аларны инвентаризацияләү вакытында Татарстанда шундый 500 бина эшкә яраксыз дип табылып, учеттан алынган. Ә менә бүгенге көндә 1100 объект элекечә үк Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының реестр учетында тора.

– Без тикшерү эшләре дә алып барабыз. Әгәр бу корылманың торышы өчен җавап бирә торган оешма үз вазифасын тиешле дәрәҗәдә башкармаса, штрафка тартыла, – дип аңлатты җитәкче.

Зөһрә МОСТАФИНА.

# Милләтара дуслык – республика имиджының аерылгысыз өлеше

**22 апрельдә Казанда III Татарстан халыклары корылтае узачак. Республика өчен мөһим булган әлеге зур вакыйганы үткәрү өстендә әзерлек эшләре башланып китте. Оештыру комитетының гыйнвар аенда Дәүләт Советында үткән беренче утырышында съездга әзерлек чорында уздырылачак чаралар һәм делегатлар сайлау тәртибе турында да сүз алышканнар иде.**

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА



addnt.ru

## КОРЫЛТАЙ АЛДЫННАН

Шәһәр-районнарга, милли-мәдәни автономия, оешмаларга һәм диаспораларга делегатлар составын формалаштыру өчен квоталар билгеләнде. Бу атнада чарага әзерләнү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитеты тагын җыелды. Татарстан Дәүләт Советы рәисе, съездны оештыру комитетын җитәкләүче Фәрит Мөхәммәтшин сүзләренчә, Татарстанның төп байлыгы – татулык, тынычлык һәм корылтайда шуңа басым ясалачак.

– Татарстанның күпмилләтле халкы, республика һәм федераль үзәк җитәкчелеге булачак бу чарага зур игътибар бирә. Аның эшендә меңнәрчә делегат һәм кунаклар катнашачак. Съезд югары оешкан дәрәҗәдә үтәргә тиеш, – дип билгеләп үтте ул.

Оештыру комитеты җитәкчесе урынбасары – Татарстан премьер-министры урынбасары Васил Шәйхразиев әйтүенчә, хәзерге көндә корылтайның символикасы өстендә эш бара. Шуңа туры китереп, «Татарстан – уртак йортыбыз» этнофестивале кысаларында да күп чаралар үтәчәк.

Съездның тарихына килгәндә, аның беренчесе Татарстанның ул вакыттагы Президенты Минтимер Шәймиев катнашында 1992 елда үтте. Анда милли-мәдәни оешмалар ассоциациясен булдыру турында резолюция кабул ителде. Шул рәвешле милли-мәдәни автономияләр һәм Халыклар дуслыгы йорты барлыкка килде. Бүгенге көндә Татарстанда 173 төрле милләт яши. Бүгенге көндә Татарстан халыклары ассамблеясы 35 милләт вәкиле мәнфәгатьләрен чагылдыручы 85 милли оешманы берләштерә. Шул елларда «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» мәгариф үзәге дә төзелә. Узган ел ул 20 еллыгын билгеләп үтте. Үзәк төрле милләт кешеләренең үз туган телләрен, үз халыкларының мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен, фольклор, җыр һәм биюләрен өйрәнә алсын өчен оештырыла. Биредә инглиз, корея, хинди кебек чит телләрне өйрәнергә; һинд, башкорт, кавказ һәм башка халык биюләре белән шөгыльләнергә мөмкин. Бүгенге көндә Күпмилләтле якшәмбе мәктәбендә 18 бүлек эшләп килә.

Моннан ун ел элек, төгәлрәге, 2007 елның ноябрь аенда – Россия халыклары көне алдыннан Татарстан халыклары корылтае икенче тапкыр үтте. Съездга 700гә якын делегат, күп санлы кунаклар җыелды. Минтимер Шәймиев анда, республиканың барлык күпмилләтле халкына мөрәҗәгать итеп:

– Республикада милли традицияләрне торгызу һәм саклауда Милли-мәдәни берләшмәләр ассоциациясенең роле зур. Аның көче белән бүген бездә якшәмбе мәктәпләре эшли, миграция мәсьәләләре чишелеш таба. Ассоциация һәрвакыт дәүләт, җирле үзидарә хакимиятенең ышанычлы хезмәттәше булды. Без бергә бик күп мәсьәләләрне хәл итә алдык. Республиканың күпмилләтле хәрәкәте 90нчы елларда Татарстандагы иҗтимагый-сәяси вазгыятьне дә җайга салырга ярдәм итте. Хәтерләсәгез, Татарстан халыкларының беренче съезды Россия тарихының авыр чорында узды: бер яктан милли үзаң үсеш алган булса, икенче яктан милләт һәм динара киеренкелекләр арткан вакыт иде, кайбер төбәкләрдә алар хәтта ачык бәрелешләргә китерде. Безнең республика исә төрле милләт вәкилләрен тынычлык һәм бердәмлек кебек гомумкешелек идеяләре белән берләштерүгә ирешә. Бу алга таба республиканың социаль-икътисади һәм мәдәни үсешен тәэмин итте. Бүген Татарстан – Россия һәм чит илләрдә аеруча үсеш алган төбәкләрдән берсе санала. Татарстан һәрвакыт төрле милләт кешеләре өчен туган йорт булды. Бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләре Татарстан территориясендә яшәүче төрле милләт вәкилләренең артуын күрсәтте. Һәм без, татарстанлылар, аларның барысына: «Рәхим итегез!» – дип әйтәбез, – дигән иде.

Икенче съездда Милли-мәдәни оешмалар ассоциациясен Татарстан халыклары ассамблеясы итеп үзгәртеп кору турында карар кабул ителде. Аның җитәкчесе итеп Фәрит Мөхәммәтшин сайланды.

Татарстан халыклары съездын уздыру традициягә әверелде, чөнки республикада милләтара һәм конфессияара татулыкны һәм тынычлыкны саклау өстенлекле юнәлеш булып тора. Толерантлык һәм милләтара дуслык – республика имиджының аерылгысыз өлеше.

**Татарстан Президенты Рөстәм МИҢНЕХАНОВ:**

*Республикада гомер итүчеләрнең яртысы татар булса, калганы – бүтән милләт кешеләре – рус, чуваш, мари... Бездә 170 милләт яши. Аларга да шартлар тудырырга тиешбез. Әйтик, мәнә академия төзибез, Казан изге ана иконасы соборын төзибез. Синагоганың 100 еллыгы булды. Менә староверлар чиркәвенә ярдәм күрсәттек. Әгәр дә ул халыкка без шартлар тудырмасак, аларга монда яшәргә кызык булмас иде. Халыклар ассамблеясы эшли, аларны тупларга, җыярга, нинди ярдәм күрсәтергә Фәрит Мөхәммәтшин бик зур көч куя. Алар аша шул халыклар белән элемтәдә торабыз. Бу эшне без бик кирәк дип саныйбыз. Әгәр дә безнең җирлектә милләтләр арасында, дин арасында тынычлык, килешү булмаса, бу җирлекнең бер киләчәге дә юк. Үзебезнең татар милләтен дә сакларга, шул ук вакытта бүтән милләтләргә дә шартлар тудырырга тиешбез. Шул юнәлештә киләчәктә дә эшләячәкбез.*

**(Республика телеканаллары җитәкчеләре белән очрашу вакытында әйткән сүзләре)**

## Сүзен-сүзгә

**Илдар ГЫЙЛЬМЕТДИНОВ,** Дәүләт Думасының Милләтләр эшләре комитеты рәисе:

– Милли мәсьәләләр һәрчак актуаль булып кала бирә, ул – иң четерекле проблемаларның берсе. Бу безнең өчен генә түгел, бөтен ил буенча шулай. Татарстанда әлеге өлкә бигрәк тә игътибар үзәгендә. Әлегрәк республика халыкларының телләрен, гореф-гадәтләрен саклау өчен дәүләт программалары кирәк дип сөйләгән булсак, бүгенге көндә алар инде уңышлы гына эшләп килә. Районнарда да Халыклар дуслыгы йортларының филиаллары ачылды. Аларда да эш системалы бара һәм менә шуңа анализ ясау өчен бер җыелышып сөйләшергә кирәк. Съездда төрле милләт вәкилләренең, җәмәгатьчелекнең фикерен дә тыңлаячакбыз. Аларны борчыган мәсьәләләр булса, вакытында хәл итәргә кирәк. Шул күзлектән чыгып караганда да, съезд республика тарихында мөһим вакыйга булып тора.

**Сергей НОВИКОВ**, мордва милли-мәдәни автономиясе рәисе:

– Күп гасырлар дәвамында рус, чуваш, мордва, удмурт, мари һәм башка халыклар үзара дус-тату яшәгән. Без бер-беребезне хөрмәт итәбез, алга таба да бу дуслык югалмасын иде. Без моны киләчәк буынга җиткерергә тиеш. Милләтләр үзләренең телләрен, гореф-гадәтләрен югалтмасын иде. Әлеге уңайдан бик күп мәдәни чаралар, фестиваль-конкурслар уздырыла. Моннан алдагы съезд ун ел элек булды, шушы дистә елда эшләнгән эшләргә хисап бирер вакыт җитте. Киләсе ун елга яңа максатлар, бурычлар да билгелисе була. Съезд ул тагын аралашу, танышу мәйданчыгы да булачак.

**Олег ТРЕТЬЯКОВ**, мари милли-мәдәни автономиясе рәисе:

– Съездда мин авылларның киләчәге, аларны саклап калу турындагы чыгышларны ишетергә телим. Тел, гореф-гадәтләр авылда саклана. Яшьләр шәһәргә китәләр дә шунда калалар. Балалар булмагач, мәктәпләр ябыла. Ә мәктәптә без үзебезнең туган телдә укытабыз. Тел, йолалар, гореф-гадәтләр буыннан буынга күчәргә тиеш.

**Тимур КАДЫЙРОВ**, Татарстан халыклары Яшьләр ассамблеясы җитәкчесе:

– Съезд ул безнең өчен мөһим вакыйга. Әлеге чара алга таба үсәргә, яңа проектлар өстендә эшләргә стимул бирә. Съезд кысаларында Яшьләр ассамблеясы мәдәни чаралар уздырачак. Шул уңайдан үзебезгә актив яшьләрне туплыйбыз. «Татарстанның мәдәни мозаикасы» фестивален, «Күптөсмерле Татарстан» исемле фотокүргәзмә уздыру уе бар.

НӘТИҖӘ

# Аучы, балыкчылар хисап тотты

**Хайваннар дөньясы объектларын саклау һәм алардан файдалану идарәсенең еллык коллегиясендә сүз кыргый хайваннарны саклау һәм, әлбәттә, аулау турында да барды.**

Татарстанның 6309,4 мең гектар мәйданында аучылык итәргә мөмкин. Шуның 1164 мең гектарына – урманнар, 518,7 мең гектарына сулыклар, сазлыклар туры килә. Республикада барлыгы 95 аучылык хуҗалыгы бар, 48,3 мең кешегә аучылык билеты бирелгән. Корылган мылтык кайчан да булса ата, дигән борынгылар. Билет алган барлык кешеләрне корал тоттырып бер рәткә тезеп куюны күз алдына китергәч, бераз куркыныч та булып китте. Болар бар да ауга йөри башласа, бер җәнлек тә калмас. Беренче карашка шулай кебек тоелса да, республикадагы һәр поши, куян, төлке, кабан дуңгызы исәптә һәм аучылык итәргә рөхсәт тә барысын исәпләп, бизмәнгә салып караганнан соң гына бирелә. Мәсәлән, бүгенге көндә аучылар кышкы маршрут хисаплавы тәмамлыйлар. Хайваннарның кардагы аяк эзләрен теркәп, аучылар Татарстан Республикасы территориясендә аларның төрлелеген һәм фаунаның биотопик бүленешен ачыкларга булышалар. Чыгарылган мәгълүматлар, үз чиратында, һәрбер төр хайван белән эшләргә нигез булып торачак. Киләчәктә браконьерларга да көн бетәчәк, законсыз ауда кулланылган барлык техника кулга алыначак.

– Хәзерге вакытта да арест законлы, әмма башка яктан караганда, ул фиктив булып чыга, чөнки тартып алынган корал шунда ук аның иясенә саклауга тапшырыла. Хәзер мин мәсьәләне башкача куйдым һәм күп кенә район башлыклары «тартып алынган транспортны районнарда саклау мөмкинлеге бар» дип раслады. Коры җирдә булсынмы ул, судамы – транспорт чарасы тартып алынырга һәм, хөкем карары чыгарылганчы, административ арестта булырга тиеш. Аннан соң суд карары буенча конфискацияләнә яки иясенә кире кайтарыла. Транспорт чараларын ияләренә кире саклауга тапшыру дөрес түгел. Тартып алырга кирәк, шул чакта нәтиҗәсе уңай булачак, – диде премьер-министр урынбасары Васил Шәйхразиев.



Күргәзмәдән фоторепортажны www.shahrikazan.com сайтыннан карагыз.

Альберт Каюмов фотосы

Бу балык инспекциясе аучылардан тартып алынган көймә, катер һәм башка төр транспортка кагыла. Алар арасында коры җирдә браконьерлар кулланган трактордан алып мотоциклга кадәр бар.

Васил Шәйхразиев балык инспекциясе һәм ау идарәсе җитәкчелегенә 10 мартка кадәр махсус саклау урыны һәм аларны урнаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләргә йөкләмә бирде. Аның фикеренчә, транспортны арестка алу законсыз аучыларны тизрәк штрафларын түләүгә һәм табигатькә китергән зыянны каплауга этәрәчәк.

Коллегия кысаларында 1-5 мартка хәтле «Балыкчы. Аучы» дип аталган XI махсус күргәзмә дә эшли.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

ЯЗМЫШ

**Түбән Камада яшәүче сыйныфташым Рәмзиянең авырганын ишеткәч, хәлен белешергә дип шалтыраттым. Хәленең бик яхшы булмавы тавышыннан ук аңлашылды. Авырып урын өстендә ята икән. Узган ел йөрәгенә операция ясаткан.**

# «Исәннәр бер кайта...»

– Әй, бетерде бу бала хәсрәте мине. Шушы айда Рамилнең гүр иясе булуына – ун ел. Һаман исләремнән чыкмый бит, – диде ул, авыр сулап. – Ирем Илсур да әле берничә ай элек кенә операция кичерде. Икебез дә ярдәмгә мохтаҗ булып калдык хәзер. Теге вәхшиләр түләргә тиешле 300 мең сум акчаларын да ун ел буе түләмәделәр. Кабат суд юлларында йөрергә мөмкинлегебез дә юк.

...Әлеге күңелсез вакыйга кабат хәтердә яңарды. 2007 елның 11 февралендә уллары Рамил, сөйгән кызы Гөлназны алырга дип, Алабуга районына китә. Алабугага барып җитү белән, өйдәгеләргә шалтырата. Тик әйләнеп кайтмыйлар, телефоны да җавап бирми. Әти-әнисе борчыла башлый, аннары, Чаллыдагы туганнарына кереп кунганнардыр дип, үзләрен тынычландырырга тырышалар. Икенче көнне кич эштән кайтышына Рәмзияне милиция хезмәткәрләре каршы ала. Әни кешене тиз генә юатырга мөмкин булмый ул мизгелләрдә. Шуңа күрә сорауларга җавапларны да, нигездә, кызлары Лилия бирә. Егет белән кызның юкка чыгуы турында хәбәр яшен тизлегендә бөтен тирә-юньгә таралып өлгерә.

Яшьләр, Алабуга борылышыннан олы юлга чыккач машиналарын туктатып, бераз сөйләшеп утыралар. Шул чагында әзмәвердәй берничә ир заты килеп, аларга машинадан чыгарга куша. Рамил, бу билгесез бәндәләрнең явызлык кылырга маташуларын сизеп: «Егетләр, машинаны алыгыз. Зинһар, безгә генә тимәгез!» – дип ялвара. Бу сүзләр вәхшиләрнең колагына да керми. Алар егетне кыйнап, кулларын бәйләп, машина багажнигына салалар да, ун чакрым чамасы юл үткәч, урман эченә алып кереп үтерәләр һәм шунда ташлап калдыралар. Бу вакытта Гөлназ юл читендәге машинада сак астында була. Ул Рамилне исән калгандыр дип уйлый. Үзен исә башка якка алып китеп җәзалыйлар, алтын бизәнү әйберләрен салдыралар һәм күпердән ыргыталар. (Шул вәхшиләрнең берсе ул алкаларны алып кайтып кызының колакларына кидерә.) Үлүенә инану өчен, кызга өстән берничә мәртәбә аталар да әле, әмма тидерә алмыйлар. Кабат янына төшеп, кулларын бәйләп, бозга таба төрткәләп җибәрәләр дә өстенә кар өеп китеп баралар. Әле дә ярый аңын җуймый кыз. Машина кузгалып китүгә, ничек кирәк алай аякка басып, үз авылын эзләп китә.

Кышкы көндә бер кат күлмәктән, яланбаш килеш ун чакрым чамасы юл үтә ул. Кайтып җиткәндә, үз авылларын танымыйча, кире борыла. Икенче бер авылда аталы-уллы яшәп ятучыларга килеп кергәч, Гөлназга чәйләр эчертеп, җылы әйберләр бирәләр һәм әти-әнисенә хәбәр итәләр. Гөлназның аяклары өши. Аны ике ай буе хастаханәдә дәвалыйлар. Егетенең үлеме хакында да шунда ишетә. Милиция хезмәткәрләре аның сүзләре буенча мәетне табып алалар.

Күп җинаятьләр кылган бу вәхши затларның берсе 25 елга, икенчесе – 23, өченчесе – 17, калганнары азрак вакытка ирекләреннән мәхрүм ителә. «Инде икесе иреккә дә чыккан. Исәннәр кайта. Минем генә бала кире кайтмый», – ди Рәмзия, күз яшьләрен тыя алмыйча. Матди зыянны түләтү буенча Алабуга районының суд приставларына да мөрәҗәгать итеп караганнар. Әмма суд карары һаман үтәлми кала бирә.

Гөлназга килгәндә, ул әлеге гаилә белән һаман да элемтәләрен өзми. Рамил исемле егетне очратып, гаилә корып җибәргәннәр. Ике бала үстерәләр.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.

ФИКЕР

# Нигә мәчеткә хатын-кызлар күбрәк йөри?

Ни гаҗәп, бүген мәчеткә ир-атларга караганда хатын-кызлар күбрәк йөри. Мөхәммәд (с.г.с.): «Хатыннарыгыз мәчеткә барабыз дисәләр – тыймагыз», – дигән. Аларның мәчеткә йөрүләрен хуплагыз димәгән. Тыю белән хуплауның бер мәгънәгә ия булмавын аңлыйбыз бит. Хәдиснең әчтәлегеннән сүзнең бүгенге кебек ярым-йорты гаиләләр турында түгел, ә бәлки тулы гаиләләр турында баруы аңлашыла.Ә безнең хәлебездә, бу дөньяда ук җәннәттә яшисе килеп, иргә сабыр итә алмыйча аерылып ялгыз җан асраучы, шуның белән үзен бәхетле санаучы хатыннарыбызга нишләргә соң? Бәлки имамнарга ялгыз хатыннар белән ирләрнең очрашу урынын мәчеттә түгел, башка урыннарда оештыру хәерлерәк булыр. Мәчет таныш-белешләр белән очрашып, хәл-әхвәл белешә торган урын түгел, Ул – Аллаһ йорты.

Бу гүзәл затларга да имамнарның аларны ничек җәннәткә кертү турында кайгыртуларын көтеп тормыйча, ялгыз бабайларга хатын булырга яки икенче, өченче, дүртенче хатын булып кияүгә чыгу турында уйлый башларга вакыт җиткәндер, әгәр ышанучылардан булып, җәннәтләрне инкарь итүчеләрдән булмасалар. Бер хәдистә: «Фарыз намазларын укып, фарыз уразаларын тотып, үлгәндә ирләре алардан канәгать булсалар, Аллаһ ул хатыннарга сигез җәннәт ишеген ачып куя», – диелгән. Моннан күренгәнчә, белем алуга бирелеп, ирләренә хезмәт итүне арткы планга күчерү һич ярамый. Хатын-кыз өчен исламда ир хакы бала, әти-әни хакыннан өстенрәк.

Илнамия ГАФФАРОВА.

# Ел укытучысы Илсур Метшинны баерга өйрәтте

УҢЫШ СЕРЕ

**2 март көнне Казан Ратушасында «Казан шәһәренең ел укытучысы» бәйгесенә нәтиҗәләр ясалды. Бәйгенең төп юнәлеше булган «Фән укытучысы» номинациясендә Мәскәү районының 2нче лицей-интернатының математика укытучысы Алмаз Хәмидуллин җиңүче дип табылды. Ул бәйгенең республика этабында көч сынашачак.**



metshin.ru

– Уңыш серем бик гади. Мин көн саен, көзгә алдына килеп, көненә 200-300 мәртәбә: «Мин – ел укытучысы», – дип кабатлый идем. *(Көлә.)* Чын күңелдән әйткән сүзләр материальләшә дигән төшенчә бар бит ул. Әлбәттә, «мин – җиңүче» дип әйтеп кенә уңышка ирешеп булмый, моның артында зур эш һәм тырышлык ята. Укытучы берүзе генә мондый бәйгеләрдә җиңеп чыга алмый, шуңа да мине әзерләгән командама, гаиләмә, мәгариф системасына зур рәхмәтемне белдерәм, – диде Алмаз.

Яшь укытучы әле бер ел элек кенә Түбән Кама шәһәреннән Казанга күченгән булган. Ә укытучы булып эшләвенә инде алты ел.

– Университетта мин математик-программист һөнәрен үзләштердем. Соңгы курсларда «мәктәптә балалар укытачакмын» дигән җитди карарга килдем. Киләчәктә укытучы булсам да, мәктәп директоры булсам да, максатым – кешеләргә файда китерү. Дәрес, бүген балаларны математика фәне белән кызыксындыру җиңелләрдән түгел. Укучыларыма берничә җавап табып була торган логик биремнәр бирәм. Балаларда ул креатив фикерләү, кызыксыну сыйфатлары уята, – диде яшь укытучы.

Конкурста барлыгы 500дән артык мөгаллим катнашты, ләкин төрле сынаулар аша финалга нибары 95е генә үтә алды. Ел саен укытучыларны Казан Ратушасында зурлап каршы алган Казан мэры Илсур Метшин да укытучы һөнәренең мөһимлеген искәртте.

– Җиңүчебез Алмаз Хәмидуллин ярдәмендә мин хәзер шәһәр өчен ничек акча эшләргә кирәклеген беләм. Бары тик көн дәвамында «шәһәргә акча кирәк» дип 200-300 тапкыр кабатларга гына кирәк икән, – дип шаяртты мэр. – Чынлыкта исә сезнең бу җиңүегез артында зур тырышлык, эшегезгә, шәһәрегезгә карата зур мәхәббәт тора. Укытучы кеше урамда да, җәмәгать транспортында да әллә каян күренеп, аерылып тора. Балаларга, кешелеккә булган мәхәббәт сездән нур булып бәркелә. Сез һәрвакыт әйләнә-тирәгезне яхшы якка үзгәртергә омтылуыгыз белән аерылып торасыз, – диде Илсур Метшин.

Бәйгенең үз яңалыклары да бар. Әйтик, быел «Татар теле һәм әдәбияты укытучысы» дигән яңа номинация өстәлде. Бу төрдә Совет районының 20нче гимназиясе укытучысы Гөлназ Галиева җиңү яулады. «Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары» номинациясе дә бәйге өчен яңалык. Әлеге юнәлештә Совет районының 8нче гимназиясе укытучысы Юлия Салюкова беренчелеккә чыкты.

**Алисә САБИРОВА.**

**Гадел Кутуй әсәренә нигезләнеп төшерелгән «Тапшырылмаган хатлар» нәфис фильмы март аеннан шәһәр һәм район кинотеатрларында прокатка чыгачак. «Яңа Гасыр» каналында аның премьерасы декабрь аенда булган иде.**

## «Тапшырылмаган хатлар» – районнарда

Фильмны Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Лениногорск, Нурлат, Питрәч, Сарман, Спас һәм Ютазы район үзәкләрендә һәм авылларында күрсәтү планлаштырыла. Әйтик, Буа районында графикка 12 авыл кергән.

Исегезгә төшерәбез, Гадел Кутуй «Тапшырылмаган хатлар»ны 1935 елда иҗат иткән. Әсәрдә 1920 елгы вакыйгалар сурәтләнә. Фильм исә бүгенге көнгә яраклаштырып төшерелгән. Фильмның продюсеры Фәрит Галиев сүзләренчә, анда күрсәтелгән проблемалар безнең көннәрдә дә бик актуаль. Рольләрдә Гүзәл Сибгатуллина, Ришат Әхмәдуллин, Айдар Сөләйманов, Фирая Әкбәрова, Илтөзәр Мөхәммәтгалиев, Фәнис Җиһаншин һәм башкалар уйный.

Сценарий авторы Дан Дамаскин һәм аның тормыш иптәше, фильмның тавыш режиссеры Илсөяр Дамаскин – илкүләм билгеле проектлар әзерләгән кешеләр.

Фильмны куючы-режиссер Рөстәм Рәшитов, куючы-операторлар Фәрит Галиев һәм Денис Гусев.

# Татарча физик тәрбия

**Казанның 162нче балалар бакчасы кечкенәдән үк сабыйларны югары уку йорты белән таныштырырга булган. Алар Казан педагогия көллияте һәм Виталий Тимирясов исемендәге Казан инновацион университеты белән үзара хезмәттәшлек итү турында шартнамә төзегәннәр.**



Хәзер уку йорты галимнәре балалар бакчасында еш кунак. Әле күптән түгел генә уртак хезмәттәшлек нәтиҗәсендә «Федераль дәүләт белем бирү стандартлары буенча мәктәпкәчә яшьтәге балаларга физик тәрбия биргәндә ике дәүләт телен өйрәтүнең яңа алымнарын куллану» һәм «Балаларга физик тәрбия бирүдә интегратив якын килү» дигән темаларга кызыклы очрашулар узган.

162нче балалар бакчасында өлкән тәрбияче Рузилә Абдуллина әйтүенчә, аларның мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе шәһәр күләмендә ресурс үзәге статусы алган.

– Педагогия көллияте, Казан инновация университеты белән берлектә узган чаралар вакытында эш тәҗрибәсе уртаклашабыз, педагогик эшчәнлектә яңа технологияләр, алымнар хакында булачак белгечләр белән фикер алышабыз. Әйтик, соңгы чараларның берсендә укыту методик комплекты авторы, Казан инновация университетының Чаллы филиалы доценты, педагогика фәннәре кандидаты Зифа Зарипованың методик киңәшләре бик файдалы булды. Казан педагогия көллиятенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Фәнүрә Шәйдуллина да үзенең кызыклы фикерләрен җиткерде, – ди тәрбияче.

«Чулпан» балалар бакчасында татар теле тәрбиячесе Надия Вәлиева, музыка җитәкчесе Ания Өметбаева, физик инструктор Альбина Сабирова төркем тәрбиячеләре белән берлектә бәйрәмнәрне, эшчәнлекләрен саф татар телендә алып баралар. Балаларга зәвык тәрбиясе бирү дә, сәламәтлекне ныгыту күнекмәләре дә ана телендә аңлатыла. Шулай ук Идел буе халыкларының фольклорын өйрәнү белән мәшгульләр. Чарага килгән кунакларның да татар телендә тәрбия һәм белем бирүче мондый бакча белән Казан шәһәрендә беренче тапкыр очрашулары икән. Бакча мөдире Рәсимә Вәлиева фикеренчә, бары балалар, әтиәниләр, тәрбиячеләр белән бердәм эшләү нәтиҗәсендә генә милли мохит тудырып була. Шуңа да балалар бакчасында һәр чарада диярлек ата-аналар да актив катнаша, балаларның сәләтләрен үстерүдә тәрбиячеләр белән киңәшләшеп эшли.

**Эльвира МОЗАФФАР.**

## Салават Хәбибуллин:

# «Авыл мичендә бәлеш пешерәсем килә»

**Эшче һөнәрен сәхнәгә алыштырган егет ул Салават. Әгәр Актанышка спектакль куярга Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты Илдар Хәйруллин килмәгән булса, аны зур сәхнәдә күрә алыр идекме икән?! Бу хакта Тинчурин театры артисты Салават Хәбибуллин үзе бик дулкынланып сөйли.**



– 10нчы сыйныфтан соң районда тракторчылар әзерли торган училищеда укып йөргәндә, бию коллективы тупладылар. Балалар бакчасыннан бирле биегәнем булмаса да тәвәккәлләдем. Аннары Инсан Хәсәенов «Агыйдел» бию ансамбленә чакырып алды. Җәй көне Президент белән Алтайда узачак Сабан туена барабыз, дип кызыктырды. Халык театры «Кыз урлау» спектаклен куйганда, шунда биедек. Спектакльне тагын да камилләштерергә Илдар Хәйруллин килде. «Театрны яратуың күренеп тора», –дип, ул мине театр училищесына үз курсына укырга чакырды. Әмма мин укуымны ташлап китәргә теләмәдем. Икенче елны тагын чакыргач, каршы килмәдем.

**– Ә өйдәгеләр?**

– Әни башта аптырап калды, аннары ризалашты. Ә училищега II курска кабул иттеләр.

**– Тинчурин театрына ничек килдең?**

– Училищены тәмамлаганда, мине Әлмәт, Кариев исемендәге, Минзәлә, Әтнә, Түбән Кама театрларына да чакырганнар иде. Казанда каласым килде. «Нәүрүз» фестивале вакытында Камал театрында эшләп йөргәндә, театр училищесы директоры миңа, шалтыратып, куңелле хәбәр җиткерде. Баш режиссер Рәшит Заһидуллин янына баргач, башта үзем турында сораштырды, аннан соң: «Син миңа ошадың», – дип эшкә чакырды. Рәшит Муллагалиевич хәзер безнең иккенче әтиебез кебек.

**– Сиңа комедиядә уйнау күбрәк килешә сыман. Үзеңә ничек?**

– Бирелгән рольне тегендигә-мондыйга аермыйм. Һәрберсенең үзенчәлеге бар. Бер генә амплуада эшләү туйдыра да. Театр ул – галәм, диләр бит. Шуңа күрә төрлесен уйнысы килә. Әйтик, «Шашкан бабай» комедия булса да, Оның роле авырлык белән бирелде. Мин аннан үзем күп нәрсә алдым.

**– «Беренче мәхәббәт»тә үзеңне лирик каһарман буларак та сынадың.**

– Марат роленә куркып кына алынган идем. Амплуам комик планда булгач, характерлы образ авыр булыр, дип уйладым. Аллага шөкер, уңышлы чыкты. Без аны һаман камилләштереп торабыз. Һәр спектакль үзенә күрә бер сынау.

**– Хәзерге яшь артистлар, театрдан тыш, үзләрен башка өлкәдә дә сынап карарга ярата...**

– Ике ел эчендә мин дә «Звезда востока», «Кәрвансарай», «Разбойник» фильмнарында төштем.

Өйдә бәлеш, өчпочмак, кыстыбый кебек милли ризыкларны яратып пешерәм. Билгеле бер рецепт буенча гына әзерләмим, тагын нидер өстим. Шуларны авыл мичендә дә пешереп карыйсым килә. Пешергән ризыкларымны дусларым мактап ашый. Нәрсә генә эшләсәң дә, аңа җан җылысын салырга кирәк.

**– Булачак хатыныңның сәхнә кешесе булуын теләр идеңме?**

–Хатын-кызның да төрлесе була. Ул башка өлкәдә эшләсә, көнләшергә дә мөмкин. Бергә эшләү яхшырактыр дип уйлыйм. Иң мөһиме: мине аңлый торган кеше булсын. Тик әлегә андый кешене очратканым юк. Мин еш гашыйк булучан, әмма ул хис озакка бармый. Иң озак гашыйк булып йөргән кыз беренче мәхәббәтем иде.

# Нәфис сүз – кеше көлдерү түгел

**Өлкән буын тамашачы сәхнәдә Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһудин кебек оста конферансьеларны күреп калуы белән бәхетле. Әнә шуларны бүгенге яшьләргә дә күрсәтәсе иде... Хәзер бездә конферансьелар юк, концертны алып баручылар гына бар. Нәфис сүз осталарыннан Айрат Арсланов, Рәшит Сабиров, Алмаз Хәмзин кебек артистларга алмаш булырдай яшьләрне күрәсе килә.**

Бүген бездә кемнәр нәфис сүз остасы булырга җыена соң? Соравымны театр училищесы директоры Гыйлемхан Мөбарәкшинга бирдем.

– Эстрада бүлеге моннан сигез ел элек ачылган иде. Башта анда Алмаз Хәмзин эшләде. Шушы вакыт эчендә шактый гына яшьләрне әзерләп чыгардык. Һәркайсы тормышта үз урыннарын тапса да, нәфис сүз жанрында эшләүчеләр аз. Бүгенге көндә әлеге бүлектә I-IV курсларда 38 бала белем ала. Алар арасында һәрьяктан талантлылар да бар. Аеруча III курслар бик талантлы. Күрәсең, нәфис сүз остасы булу гына аларны канәгатьләндерми. Үзләрен җыр өлкәсендә дә сынап карыйсылары килә, – ди Гыйлемхан әфәнде.

Курсның җитәкчесе Марсель Мәхмүтов фикеренчә, бүген татар эстрадасы җыр һәм пародия белән генә чикләнә. Ул безне үз дәресенә чакырып, эшләү алымнары белән таныштырды. Бу юлы «Ужин дураков» дигән француз комедиясен студентлар үзләре русчадан татарчага тәрҗемә итеп килгән иде. Шуның уңышлысын сәхнәләштереп, студентларның бөтен мөмкинлекләрен ачып, май аенда сәхнәдә күрсәтергә җыеналар.

– Без дүрт ел буена шушы студентларның сәләтле икәнлекләрен исбатларга тиеш. Әлеге төркем белән IV курста клоунада буенча дәресләр үткәрергә уйлыйм. Быел май аенда, Җиңү көне уңаеннан, Казанның тарихи урыннарын «кузгатырга» исәплибез. Әлек сугышка киткәндә, хәзерге Санкт-Петербург урамыннан җырлап үткәннәр һәм цирк бинасы янындагы мәйданда җыела торган булганнар. Без ул тантанага шул чорда иҗат ителгән шигырьләр әзерлибез. Студентларыбыз декабрь аенда яшь режиссерлар лабораториясендә катнашып, Мактау грамотасына лаек булдылар, – дип сөйләде Марсель Мәхмүтов.

Студентлар нинди максатларны күздә тота соң?

Минтимер Насыйбуллин (Балык Бистәсе районыннан) укуын армия сафларыннан кайткannan соң дәвам итә. Киләчәктә үзен алып баручы итеп күрә. Алып баручы төрлесен булдырырга тиеш, әмма теләсә нәрсә сөйләп кеше көлдерергә кирәкми, дип саный.

Рәфинә Гобәйдуллина башта җырчы булырга нияtlәсә дә, киләчәк планнары үзгәргән. Чөнки биредә татар классиклары иҗатына мәхәббәт тәрбияләгәннәр. Сәхнәдә шаян хикәяләр, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт шигырьләрен яратып укый.

Энҗе Йосыпова кечкенәдән апасы Чулпанның җырлавын тыңлап сәхнә артында йөргән чакларын искә алды. Башта биюче булырга теләсә, хәзер үзен радио-телевидениедә алып баручы буларак күрәсе килә.

Ләйсән Миннәхмәтова мәктәп елларында ук Алабугада мәдәни чаралар алып барган. Бу эшне профессиональ дәрәҗәдә дәвам итү өчен белем кирәк. Сәхнәдә үзе язган шигырьләрне дә укырга ярата.

Эстрада бүлеге укытучысы, Татарстанның атказанган артисты Инсаф Абдулла әйтүенчә, балалар театр училищесына мәктәптән әзерлексез килә.

– Алар әдәбиятны, классик язучыларыбызны белми. Бу, әлбәттә, укытучының эшләп бетермәве. Укытучыларның кызыксындыруы юк, күрәсең. Мин дәресне классик әсәрләргә, халык авыз иҗатына нигезләнеп алып барам. Сатирик язучыларның әсәрләрен өйрәнүне, яшь шагыйрьләрнең иҗатлары белән таныштыруны да максат итеп куям. Нәфис сүзне «кеше көлдерү» дип кенә аңлыйлар хәзер. Башта студентлар эстраданы «җыр» дип кенә күз алдына китерсәләр, соңрак юнәлешләре күп булуын аңлый башлый. Бездә укыган бала теләсә кайсы юнәлешне сайлый ала. Курстан берничә генә булса да, үзенең татарлыгы белән горурланып, үзләренең матур сөйләмнәрен тамашачыга җиткерә ала торган артист чыкса, үз бурычымны үтәдем, дип санар идем, – диде Инсаф Абдулла.

*Сәхифәне Люция ХӘБИБУЛЛИНА әзерләде.*

## «Ел остазы» Рабит Батулла:

# «Башка бер милләтнең дә «Сәләт»е юк!»

**Сәләтле балалар һәм яшьләргә ярдәм итүче республикакүләм «Сәмрух» премиясенең «Ел остазы» номинациясе аерым игътибарга лаек. Шәхеснең шәхес булараk формалашуында иң зур урынны укытучы кеше алып тора бит.**



Быелгы премиядә «Ел остазы» исеменә күренекле татар язучысы, драматург, публицист Рабит Батулла һәм тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, академик Индус Таһиров лаек булды. Чын остаз нинди сыйфатларга ия? Бүгенге татар мәдәниятен саклап калу өчен, яшьләр белән нинди эшләр башкарырга кирәк? Сәләтнең татар милләте тормышында тоткан урыны нинди? Бу хакта аксакалларыбыз белән әңгәмә кордык.

**– Укытучы, мөгаллим, остаз дибез. Бу сүзләрдә, чыннан да, бик зур мәгънә яшеренгән. Бүгенге меңләгән сәләтле яшьләрнең остазы булып торасыз. Сезнең остазларыгыз турында да кыбрәк беләсе килә.**

**Рабит Батулла:** – Мин әдәбиятчы буларак сүзнең килеп чыгышына бәйләнәм инде. *(Көлә.)* «Остаз» дигән сүз бар, «остат» дигән бар. Алар бер тамырдан чыккан сүзләр. Остат – шул оста дигән сүздән алынган, һәр эшнең үз остасы була дип сөйләшәбез, һәр эшкә сәләт кирәк дибез. Ә остаз төшенчәсе исә үз эченә «тәрбияче», «укытучы» дигән мәгънәне дә ала. Минемчә, укытучы кеше гадел дә, шул ук вакытта кырыс та була белергә тиеш. Остаз бит ул белем дә бирә, кешене дә тәрбияли.

**Индус Таһиров:** – Остаз махсус рәвештә өйрәтми ул. Яши, шул яшәеше белән туры юл күрсәтә. Ул үрнәк, матур бер мисал, өлге кебек. Остаз булу – дәрес бирү генә түгел. Аңа карап яшь буын өйрәнә, үрнәк ала, киңәшенә колак сала, тәҗрибәсенә таяна. Инде бүген үк яшьләр арасында үзебезгә үрнәк кешеләр, сокланырлык шәхесләр бар. Димәк, тормыш дәвам итә.

**Р.Б.:** – Юлымда яхшы укытучылар күп очрады, шөкер. Үземнең остазым дип Бакый Урманчены саныйм. Гәрчә мин рәссам түгел. Төннәр буе да сөйләшеп утыра ала идек. Мин аның эшләрен, хезмәтләрен дә дәвам иттем. Нәкый Исәнбәт тә минем остазым. Нәкый ага тарих, әдәбият буенча туры юл күрсәтә белде.

**И.Т.:** – «Сәләт»нең тагын бер укытучысы Әнвәр Хәйрине дә искә алмасак, дөрес булмас. Аның кебек тырыш кешене мин белмим. Әнвәрне бит өйрәтүче булмады, үзлектән иске һәм яңа гарәп графикасын өйрәнде. Белгәнне башкалар белән дә уртаклашырга омтылды. Узган елны «Сәләт» үздырган Әнвәр Хәйри укуларында катнаштым. Искиткеч кичә булды. Фикердәшебезне шулай зурлаганга рәхмәт! Бу укулар киләчәктә дә дәвам итсен иде.

**– «Сәләт – кичә, бүген, иртәгә» дигән сүз чыкса, сез нәрсә әйтер идегез?**

**Р.Б.** – «Сәләт»нең күзгә күренерлек нәтиҗәләре бар. Сер түгел, кичәге «сәлкеш»ләр бүгенге көндә зур урыннарда җитәкчеләр. Иҗат, сәнгать, мәдәният өлкәсендә дә адым саен сәләтлеләр. Бу бит нәтиҗә. Үземнең ике улым да «Сәләт»тә үсте. Бик теләп баралар иде, кечкенәдән татарча аралашып үстеләр. «Сәләт» – тоташ агым бит ул, зур хезмәт, киләчәккә өметләр. Башка бер милләтнең дә «Сәләт»е юк! Шуңа куанып йөрим. Биләрдәге «Сәләт» форумында төшерелгән видеоязмаларны карагач, горурлык хисе туа: андагы сары киемле «сәлкеш»ләрнең күплеге… Бу көч кенә түгел, бу – куәт! Юк, куәт кенә дә түгел әле, бу – кодрәт!

**И.Т.** – «Сәләт» – телебезне саклау мохите, шунысы белән аеруча горурланам. Ул, чын мәгънәсендә, алга бара торган, татарлыкны ныгыта, телебезне алга сөрә торган җәмгыять. Мөмкинлекләре елдан-ел арта. Биредә тел, рух һәм акыл бердәмлеге, дибез. Бу дөрестән дә шулай. «Сәләт»нең бүгенге яшәеше – татарлыкның чагылышы ул. Татарлар бүгенге көндә Рәсәйдә яшәү мисалын бирәләр, аның терәге булып торалар. Мин ышанам: киләчәктә безнең яшьләребез тагын да зуррак үрләргә ирешерләр әле!

## ПОЧТАДАН

# Безгә театр килде

**Олы Кариле авылы мәдәният йортында 11 февраль көнне Казан дәүләт аграр университеты студентлар татар театры драматург Илгиз Зәйниевнең «Мәхәббәт турында риваять» дигән мелодрамасын куйды.**



Олыкарилеләр бу көнне түземсезләнеп һәм кызыксынып көтте, чөнки мелодрамадагы төп рольне авылыбыз егете Илнар Идрисов уйнаячагын белә иде.

Тамашачы әсәрнең авторы Илгиз Зәйниев турында хәбәрдар булса да, сәхнәбезгә аның әсәре менгәне юк иде. Аның иҗаты белән танышу теләге дә, әлбәттә,зур иде.

Ул көн килеп җитте. Күрсәтелгән вакытка тамашачы да җыелды, буш урыннар калмады да. Залда якты, җылы, һәр җирдә пөхтәлек. Кемнәрдер залның зәвыклы бизәлешен күзәтә. Күрсәң, алар башка авыллардан килгәндер, тәрәзә һәм сәхнә пәрдәләре чынлап та бик матур.

Пәрдә ачыла. Сәхнәдәге күренеш-бизәлеш күңелгә бик тә хуш килерлек: агачлык, инеш, инеш аркылы басма.

Әсәрнең эчтәлеге гади генә кебек. Яшьләр кичләрен су буенда очраша, дуслаша, ярату хисләрен белдерә. Төп герой Айназ, суга төшкән ай кызы Айсылуны күреп, гашыйк була. Ай кызы да егетне ярата. Аның да җиргә төшеп, кешеләр арасында сөйгәне белән бәхетле яшисе килә. Ләкин салкын ай аны җиргә җибәрми. Аерылышу котылгысыз.

Айсылу белән Айназның матур мәхәббәтләренә киртә булырдай кешеләр җирдә дә бар. Алар яманлык кылырга да сәләтле. Алар ай кызына китәргә кушалар, хәтта җәберлиләр дә. Әсәр эчтәлеге тамашачыга әдәп-әхлак кагыйдәләрен дә оста җиткерә. Вакыйгалар үсешендә чын мәхәббәт, яхшылык, яктылык яманлыкка каршы куела. Ай кызы китә, ләкин мәхәббәт күңелдә яши, җылыта, яктырта, яшәргә көч бирә.

Пьеса авторы Илгиз Зәйниев һәм режиссер Раушан Шәриф геройларның хис-кичерешләрен калку итеп күрсәтүдә музыкаль бизәлешне оста файдаланганнар. Җырларның көе-сүзе, башкару осталыгы тамашачы күңелен ялый алырлык. Сәхнә, артист, тамашачы бергә дулкынлана, залдагы һәр кеше яшьлек, матурлык белән бергә яши башлый.

Сәхнә геройларының киемнәре зәвыклы, төсләр матурлыгы үзара килешле, авторның әйтергә теләгән фикерен ачуда булышырлык итеп уйланылган, шулай сайланган. Артистларның уены чыннан да сокланырлык. Барысы да җыр-биюгә оста, сәхнәдә хәрәкәтләре матур һәм урынлы, сүзләрне әйтү ачык, тавыш тоннары бай, сөйләм осталыклары мактарлык. Әсәр бербөтен, бер сулышта карала.Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Роберт Галиев – чын остаз. Аның театрга чын күңелдән бирелгән булуы, үзенең артистларын яратуы, кайгыртучанлыгы күз карашыннан ук сизелә. Мелодрамада ул бабай ролен башкара. Роберт абый сәхнәгә чыкса, сәхнә яктыра, нурлана, уңай энергия тарала.

Үзеңнеке үзәктә, диләр, шулай икән шул. Тамашачылар авылдашыбыз Илнар уйнавын дулкынланып, аның өчен җан атып карады. Сынатмады Илнар, сөбханалла! Буй-сын, гәүдә җиңеллеге, җыр-биюгә осталык, хәрәкәт тизлеге, хис тирәнлеген бирүдә тавыш үзенчәлекләрен оста файдалана белү, гаҗәеп ихласлык – барысы да бар. Күз тимәсен!

Шәп уйнадылар егетләр-кызлар. Тамашачы бик риза булды. Алып кайткан бит авылга Илнар сәхнәдәш дусларын. Җырчы булырга укучы авылдаш егетебез Марат Галимҗанов та алданрак Динә һәм Рафаэль Латыйповлар белән бергә искиткеч шәп программа әзерләп кайткан иде. Менә инде 18 мартта Венера Ганиева белән безгә тагын киләчәкләр.

Егетләр мәктәптә үзешчән сәнгать түгәрәгендә, төрле тематик чараларда катнашып, сәнгатькә тартылдылар. Аннары сәләтләрен мәдәният йортында Илсур абыйлары җитәкчелегендә чарладылар, үстерделәр. Соңгы елларда мәдәният йорты коллективы үзенең эшчәнлеген бик киңәйтте, төрләндерде. Район һәм зона бәйге-ярышларда урыннары һәрвакыт югары. Авылыбызның йөзек кашы булган артист, режиссер, Минзәлә театры директоры, Тукай бүләге лауреаты Сабир Өметбаев исемен дә безнең авыл мәдәният йортына юкка бирмәгәннәрдер.

**Нәкыя ХАЛИКОВА,**
ветеран укытучы.
Кама Тамагы районы,
Олы Кариле авылы.

ХИКӘЯ

# КАЗ КАНАТЫ

**Лүзия САЛИХОВА**

Ул елны кара ана казның бәпкәләре булмады. Кара ана каз – Зифа әбинең җыйнак кына, акыллы казы. Башка елларны ун һәм аннан да күбрәк була иде бәпкәләре, ә быел... Салган йомыркаларын ай чамасы җылытып арып-йончып беткәч, Зифа әби кат-кат тикшергәннән соң барысын да ташларга булды, чөнки кайсысы буш, кайсысы бозылган иде.

Өч-дүрт ел буе хуҗасын горурландырып, тирә-юньне шатландырып яшәде тыйнак кош. Түгәрәк зәңгәр күзләре кояшлы күк йөзенең бер кыйпылчыгы төсле иде. Кара-яшелле бәпкәләрен – кечкенә йомры йомшак йомгакларын иртәтеп ишегалдында йөргәндә, дөнья тагы да ямьләнеп, түгәрәкләнеп китәр сыман иде. Язга сөенеп очынган сыерчыклар тагын да дәртләнебрәк сайрый башлый кебек; болдырда сыртын җылы кояшка куеп яткан мәче дә, күзләрен назлы кысып, һәр бәпкәне барлап чыгар; көтүдән кайткан сыер да, ашыккан җиреннән туктап казның бәпкәләрен җыйнаштырып, кырыйга чыгып юл бирүен көтеп торыр иде. Хуҗабикә үзе дә, йорт-каралтыдагы һәр җан иясе дә казга ихтирам һәм хөрмәт белән карый иде.

Ә бу җәйдә борын очы белән сәлам, үлән чукыштырып, үз-үзенә бикләнеп, уйланып йөргәндәй битараф карашлы каз ашау-эчүгә дә игътибар итми башлады. Сабыр-моңсу кошның бу халәте әбинең йөрәген әрнетте. Зифа әби – җиңел-җитез хәрәкәтле, ачык зәңгәр күзләреннән нур сирпеп, һәрбер кешене балавыздай эретеп сөйләшә белүче карчык. Хәер, аңа карчык дип әйтү дә килешми бугай: киемнәрнең ачык төслеләрен генә кия, көлмичә сөйләшми дә, батыр йөрәкле кеше. Буй-сыны җыйнак булганга, авылдашлары аны, үз итеп, «Бәләкәй әби» дип йөртә. Ире сугышта югалган, кечкенә дүрт баланы берүзе тәрбияләп үстергән мөлаем йөзле кеше ул. Һәр сүзгә җавабы әзер, беркайчан да югалып калмый торган җор телле, эш сөючән чын авыл карчыгы.

Казының кайгысына Зифа әби бөтен җаны-тәне белән әрнеде. Иртән намаз укыганда да, кичтән алсуланып кояш баткан-да да, мал-туарын карап, гөжләтеп сыер сауганда да шушы казы турындагы уйлардан арына алмады. «Йа Раббым, нигә ятим иттең инде бу гөнаһсыз җан иясен?» – дип өзгәләнде.

Каз, дөньядан көннән-көн ныграк ваз кичкәндәй, һәр нәрсәгә битарафрак була барды. Сизелер-сизелмәс кенә исеп куйган җил дә кузгатырлык булып ябыкты. «Җаныем, чирлисеңме әллә?» – дип, Бәләкәй әби аны итәгенә утыртып сөйде, аякларын, борынын тотып карады. «Кайнар да, салкын да түгел, гадәти генә, ниләр булды соң сиңа, бәгырькәем?» Аннары казның күзләренә карап алды. Казның күз карашыннан сары-йомшак чәчәкләр арасында йөрүче, яшел үлән өстендә кояшта изрәп йоклаучы нәни бәпкәләрне юксынуы сизелә иде. «Борчылма ул кадәр, ял ит, сыйлан, матурым, булыр бәпкәләрең, боерган булса», – дип юатты аны Бәләкәй әби. Каз да, килешкәндәй, йомшак кына итеп, яратып, әбинең бармакларын тешләштерде, башын әбинең күкрәгенә терәде.

Серләшеп, моңаешып утырганда күңел бушангандай булса да, кара казның кайгысы кимемәде. Олы капканы чыккач та башланып киткән болын-күл буен тутырып йөргән, йөзгән каз бәпкәләрен



күрмәс өченме, ишегалдыннан да чыкмады, ә соңрак сарайның бер почмагында кымшанмыйча тик утыруында булды.

Кояшлы, җылы көннәрнең берсендә Бәләкәй әби посылка тартмасы тотып кайтып керде. Өстендә озын җиңле, киң итәкле ал күлмәк, өстеннән ак алъяпкыч япкан, чәчәкләр төшкән ак яулык чөеп бәйләгән. Ишегалдын күздән кичергәч, сарай эченә атлады. Караңгыга күзе ияләшә төшкәнче бер мәл тын гына басып торды.

– Ли-ли-ли! – Безнең якта казларга шулай дәшәләр. Каршы тавыш-тын ишетелмәгәч, кулындагы тартмасын җиргә куеп эчкәрәк атлады.

– Кил-кил, ли-ли-ли! – дип дәшкәләп, сарай почмагында тын гына утырган казны күтәреп, ишегалдына алып чыгып бастырды.

Көн яктылыгы, кояш нуры казны сискәндереп җибәрде. Ул чайкалыбрак китте дә, «лып» итеп, җиргә утырды, муенын сузып, сәлам биргәндәй, башын як-якка игәләп, борынын җиргә тидергәләп алды. «Исәнме, Җир-ана, яшел үләннәр, саумы, дөнья!» – диде бугай.

Әби сарайда калдырган посылка тартмасын каз янына җитез генә алып килде дә: «Хәзер, хәзер, матурым», – дип, аннан бер почмакка өелешкән үрдәк бәпкәләрен икешәрләп-өчәрләп алып җиргә тезә башлады. Әле генә йомыркадан чыккан чуар нәни җан ияләре, әбиләре ничек куйган булса – шулай катып кала бирделәр. Зифа әби, күлмәгенең киң итәген җыештырып, чирәмгә утырды да уң кулы белән ана казның аркасыннан сөйде, ә сул кулы белән бер йомгак булып укмашып торган ун үрдәк бәпкәсен каз тарафынарак этәрде. Үзе исә:

– Йәгез әле, танышып алыгыз, менә бу әниегез булыр сезгә, ә болар сиңа бәбиләр, – дип, йөзеннән нур чәчеп елмаеп сөйләнде.

Кошлар алдына таба белән су, савыт тутырып җим куйды. «Йа Ходаем, үзеңә тапшырдым», – дип, өенә юнәлде. «Самавырны гөжләтеп алмый булмас...»

Хуш исле кайнар чәй эчкәндә, тәрәзә аша ишегалдын күзәтте. Каз, әкрен генә, аякларына басты, күкрәген киерә төшеп, аптырап-куркып торган нәни үрдәк бәпкәләре тирәли салмак кына йөреп алды. Бу сабыйлар язмышы миңа тапшырылды бугай, дип көрсенгәндәй, җитди-моңсу иде аның үз-үзен тотышы. Нәниләргә дә тыныч-рәхәт булып китте, аларның кайсысы чүмәште, кайберсе үлән чемченә башлады. Әле иртәнге як булуга карамастан, якты кояш шактый биектә юмарт кына кыздыра, аксыл-зәңгәр күк йөзендә күбектәй ак болытлар тирбәлә. Каз, каурыйларын кабартып, дулкынлатып алды, иелеп, табадан су эчте. Аның хәрәкәтләре гүя нәни бәпкәләргә багышланган иде: гүя сез дә шулай итегез, авырмыйча, таза булып үсегез, дус булыйк, дия иде. Үрдәк бәпкәләре дә бу җылы карашны тойдылар бугай, чем-кара күзләрен тутырып карап алдылар да яшел үлән арасында изрәп үк киттеләр.

Чәен тәмамлап, табынны җыеп алгач, Бәләкәй әби чыгып койма ышыгына утырды. Җәйге йомшак җил аның йөзен, кулларын сыйпап узды.

Карлыганнар тулышып, кызарып-каралып, суган кыягы, кишер яфраклары түгәл тутырып хәтфәдәй яшәреп утыралар. Кыяр, кабакның сары чәчәкләреннән бал исе килгән, җәй патшалык иткән чак. Бәрәңге сабаклары яхшы ук үсеп китеп, яфраклары куе-яшел төстә, араларында чүп үләненең әсәре дә юк, төпләре өелеп куелган. Зифа әби, эшчән кулларының бармак буыннарын санап тәхлил әйткәндә, гүзәллек, бәрәкәт бөркегән тирә-юньгә карап хушланды. Чирәм арасында күренеп киткән бәпкәләр, горур-уяу кара әнкә каз күңелен нечкәртте, җанына канәгатьләнү хисе инде. «Йа Раббым, ил-көнгә иминлек бир, рәхимле җәйләр насыйп булсын».

Әби, салмак кына, урыныннан кузгалды. «Аллага шөкер, бар да күңелдәгечә булды, исәнлек бир, и Ходаем».

Көннәр җылы, матур торды. Ике-өч көн дигәндә, бәпкәләр тернәкләнеп, үсеп киттеләр. Үрдәк үрдәк инде ул, аңа су кирәк. Нәфис казларга төс чиста су түгел, озын борыны белән болгатып, арасында ком, җим, үлән тамыры булган былчырак су кирәк. Ана каз, йомшак кына тавыш биреп, үзләрен елгага чакырса да, шаян-елгыр үрдәкчекләр юл буендагы колонкадан аккан су канавына ашыктылар. Нишлисең, каз аларның артыннан иярде. Үземнекеләргә ничек тә риза дигәндәй, таш кыядай мәгърур басып, игътибар белән күзәтеп торуын белде. Яраткан казының әрсез үрдәк бәпкәләре артыннан ияреп йөрүенә әбинең бераз эче пошса да: «Ярар, күз алдында булулары хәерле, үсә төшкәч алып төшәрмен елгага», – дип уйлады.

Яхшы тәрбия нәтиҗәсеме, үрдәк бәпкәләре көр холыклы, шаян күз карашлы, сап-сары борынлы, ак мамыклы иде. Кызыл тәпиләрен сузып, җылы кояш нурлары астында черем итеп ятуларына һәр узган кеше соклана иде. Үрдәк бәпкәләре суда чыпырдасалар да, тәгәрәшеп ял итсәләр дә, ана каз уяулыгын җуймады, ул һәрвакыт иртәдән кичкә чаклы аяк өсте торды. Ләкин беркайчан да үрдәкчекләрне канаты астына алмады, яннарына кул сузымы арадан якынрак килмәде. Шулай да тилгән, карга, саесканнан саклады, усал песи, этләрдән тидертмәде. Зифа әбинең тугры кошы үз бурычын җиренә җиткереп үти белә иде.

Үрдәк бәпкәләрен каз белән кушкан вакыттан соң айга якын гомер үтеп тә китте. Җылы, кояшлы көн иде. Алдагы көнне кичтән ява башлаган яңгыр иртәнге якта туктады. Зифа әби сыерын көтүгә куып кайткач, бәпкәләрне елга буена алып төшмәкче иде. Үрдәк бәпкәләренең бер алдына, бер артына төшеп, каз Бәләкәй әбигә булышырга тырышып карады. Ләкин үрдәк балалары, өйрәнгән гадәт буенча, юл буендагы канау ягына борылдылар. Әби чакырса да, каршыларына төшеп, елга ягына куып караса да, үрдәк бәпкәләре куркышып, тавыш-тын чыгармый гына гаҗәпләнеп, бер әбигә, бер казга карап катып калдылар. Янәсе, нигә кирәк бу гамәл, болай да бик әйбәт иде бит әле. Әби дә, каз да, аптырашып, бер-берсенә караштылар: «Газапламыйкмы әллә бу нәниләрне, тора-бара аңларлар әле».

Зифа әби тирән сулыш алып көрсенеп куйды да, казга карап, башын чайкап алды. Нишләтәсең бит, һәр җан иясенең үз тормышы, янәсе. Аксыл мамык белән капланган сары соскы борынлы ягымлы бәпкәләр, бер йомарлам булып җыелып утырып, черем итеп алдылар да, юл буендагы сулы канауга юнәлделәр.

Көн гадәттәгечә дәвам итте. Үрдәк бәпкәләре туйганчы, күңелләре булганчы кечкенә сулыкны таптап, томшыклары белән казып бутадылар да, коенып чыгып, яшел куе чирәмдә ял иттеләр. Яннарында һәрвакыт уяу, сабыр, ышанычлы, мәрхәмәтле кара каз. Җылы кояш нурларында изрәп, тынычлап йоклап китте ун нарасый, хәтта үзләре турысына җиңел машина килеп туктавын да сизмәделәр кебек, тик бер-икесе генә кара күзләрен ачып, машина ишегеннән үзләренә текәлгән юан ханымга битараф карап куйдылар. Рульдәге ир-ат белән әлеге ханым тиз-тиз генә ни турындадыр сөйләшеп алдылар. Урта яшьләрдәге кыска итәкле ханым машинадан җитез генә чыгып, үрдәкләргә якын ук килеп чүгәләде. Кулындагы дәү чүпрәк сумканы таратып җибәрде дә уяныргa да өлгермәгән бәпкәләрне бер-бер артлы шунда салды. Ана каз, баскан урыныннан атылып, хатын-кызга ташланды, томшыгы белән чүпрәк сумканы кысып тешләде: «Бирмим!» Чәчен кыска итеп кистереп бөдрәләткән тулы тәнле, юан аяклы ханым, корт чаккандай сикереп торып, машинага таба йөгерде. Шул арада калын үкчәле туфлие белән казның түшенә каты итеп тибеп җибәрергә дә өлгерде. Машина күз ачып йомганчы юк булды. Урамда ал чәчәкле тигәнәк өстендә очынган күбәләк, бал кортларыннан башка җан иясе юк. Капка ышыгында яткан аклы-кызыллы сөйкемле бозау, колакларын селкеткәләп алса да, күзләрен йомып черем итә иде.

Әнкә каз «лып» итеп җиргә утырды да башын чирәмгә салды, күз аллары караңгыланып берни күрмәс, берни ишетмәс булды. «Бәләкәй әби нишләр инде? Ничек күзенә күренерем?!» Казның кайгысын беркем аңларлык түгел, ул күкрәгенең әрнеп авыртуын да сизмәде, күңеле сызланды, бар теләге мәңгелеккә онытыласы килү иде. Җылы кояш нурларында ялтыраган чык бөртегедәй кибеп юкка чыгасы иде... Күзләрен йомып, җиргә сеңәрдәй булып тынып калды. Ул, кайнар сулышлы борынын канат астына яшереп күпме вакыт узганын сизмичә черем итеп, төшләнеп алды.

→ Ахыры 10 март санында.

# Менә дигән волейболчылар үсә

**Татарстан Республикасының Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгында республиканың Волейбол федерациясенең хисап тоту-сайлау конференциясе узды. Федерация президентын һәм җитәкчеләрен дә сайладылар.**

Җаваплы вазифа бер тавыштан Татарстанның Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшинга тапшырылды. Ул кабат биш елга Волейбол федерациясенең президенты итеп билгеләнде. Оешманың җитәкчеләре дә элеккеге составта калды.

– Бу авыр, күп вакыт таләп итә торган эш. Ләкин миңа ышанасыз икән, каршы килә алмыйм. Республикада волейбол спортын үстереп зур эш башкарабыз, – дип рәхмәт сүзләре җиткерде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ул узган биш еллык эшкә нәтиҗә дә ясады.

– Волейбол – очсыз һәм һәр кеше шөгыльләнә ала торган спорт төре. Татарстанда ул актив үсеш алды. Бүген безнең федерация республикада иң яхшылар рәтендә. Ирешкән уңышлар белән генә юанмыйча, үсүне дәвам итәргә кирәк. Яңа максатлар куябыз. Бердәм булганда, без яңа проектларны башкарып чыгачакбыз, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Ул шулай ук соңгы елларда профессиональ спорттан тыш, массакүләм һәм студентлар волейболын үстерүдә зур эш башкарылуын билгеләп узды. Волейбол инфраструктурасы да үсте. Хәзерге вакытта республикада Волейбол федерациясе филиаллары булдырыла, тренерлар һәм хөкемдарларның профессиональ квалификациясе үсә.

Бу фикерне яшьләр эшләре һәм спорт министры Владимир Леонов та ныгытты.

– Бүген балалар, яшүсмерләр, студентлар арасында волейболга зур игътибар бирелә. Спорт ветераннарына да һәр яктан ярдәм итеп торабыз. Хезмәт коллективларында, предприятиеләрдә, авыл җирлегендә дә волейбол белән шөгыльләнергә мөмкинлекләр артты, – диде ул.

Владимир Леонов шулай ук республикада волейбол үсешенә танылган спортчы Екатерина Гамова мәктәбе ачылуы да зур этәргеч бирде, дип белдерде. Якын киләчәктә әлеге мәктәптә кызлардан тыш егетләр волейбол командасын да әзерләячәкләр.

СПОРТ





**Бу көннәрдә Казанның Гимнастика үзәгендә спорт гимнастикасы буенча Россия чемпионаты үтә. Ул 5 мартка кадәр дәвам итәчәк. Биредә илнең иң яхшы 150 спортчысы халыкара ярышларда катнашу мөмкинлеге өчен көч сынаша.**

Россия чемпионатының инде беренче җиңүчеләре дә билгеле булды. 1 март көнне барган ярышларда Мәскәүнең хатын-кызлар командасы алтын медаль яулады. Команда составында Татарстан кызлары булган Идел буе федераль округы командасы әлегә дүртенче урында. Республика данын Илсия Әминова белән Дарья Лопатина яклый.

Ярыш нәтиҗәсе буенча 15-23 апрель көннәрендә Румыниядә булачак Европа чемпионаты катнашучылары билгеләнәчәк. Шулай ук үзен күрсәткән иң яхшы спортчыларга сентябрь ахырында Канадада узачак дөнья чемпионатында да әләгү мөмкинлеге бар.

Соңгы Олимпия уеннары нәтиҗәсендә Россия спорт гимнастикасы буенча өченче урында бара. Безнең көндәшләр – Кытай, Япония. Шулай ук Бөекбритания һәм АКШ спортчылары да иң көчлеләр сафында.

* * *

**21 май көнне узачак «Казан марафоны»ның яңа маршруты билгеле булды. Быел спортчылар Казан Кирмәне территориясеннән йөгерә башлаячак, финиш та шунда ук булачак.**

42,4 чакрым аралыкны йөгерүчеләр Сибгат Хәким, Декабристлар, Сул як Болак, Татарстан, Шиһабетдин Мәрҗани, Марсель Сәлимҗанов, Вишневский урамнары буенча, Миллениум күпере, Карл Маркс урамы, Кремль яр буе буенча йөгерәчәк.

Марафонда 20 меңгә якын кеше катнашыр дип көтелә.

Алисә САБИРОВА әзерләде.

**Күптән түгел генә Венгриядә Аяз Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога!» дигән китабы венгр телендә чыкты. Китапның тиз арада тәрҗемә ителүе Казан дәүләт федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты галимнәрен дә гаҗәпләндергән.**

# «Йәгез, бер дога!»ны Венгриядә укый башладылар




Аның директоры Рифат Җамалетдинов 24 февральдә Будапештта китапны тәкдир итү кичәсе булуын җиткерде. Доцент Миләүшә Хәбетдинова Аяз Гыйләҗев әсәрләренең алты томлыгын туплаган, аларны чыгаруда Мәдәният министрлыгы матди ярдәм күрсәткән. Директор киләчәктә Будапешт университеты белән элемтәләр булдырырга ниятләвен дә әйтте.

– Мин әдәбият өлкәсендә дөньяга чыгара торган йолдыз эзләдем һәм Аяз абыйның иҗатына тап булуым белән бәхетле. Әлеге китапта татарның үткәне, киләчәккә васыяте урын алган. Аяз абый лагерь турында гына язмый, татарга дога укый. Китапны Андрош Шопрони белән Юдит Виртен тәрҗемә иткән. (Андрош Шопрони – Достоевский, Толстой, Чехов әсәрләрен дә тәрҗемә иткән кеше.) Венгриядәге «Әлифба» татар җәмгыяте идарә рәисе Рита Хәсәнова тәрҗемәчеләрне тапты, – диде Миләүшә ханым.

Журналистларны китап белән Рита Хәсәнова таныштырды.

– Китапны чыгаруда «Гулаг» фонды ярдәм итте. Ул 25 мең еврога төште. Китапның ике ай ярым эчендә чыгуына үзебез дә гаҗәпләндек, – ди Рита ханым.

Ул моннан берничә ай элек кенә Аяз Гыйләҗев белән ГУЛАГ лагерьларында бергә булган Арпад Голгоциның Казаннан җылы тәэсирләр белән кайтуын да әйтте. Аңа Казан бик ошаган. «Казанда безнең яңа гаиләбез барлыкка килде», – дип, сөенечләре белән уртаклашкан.

Китапның тышлыгына килгәндә, аның рәсемен Мансур Гыйләҗев сайлаган.

– Тышлыкта – Арпадның лагерьда ясаган рәсеме. Без аны бик уңышлы дип санадык. Язмышы катлаулы булса да, әти зарланмады. Мин элек, ничек шулай лагерь елларын сагынып була, дип гаҗәпләнә идем. Аның китабын укыгач, аңлый башладым. Арпад Голгоцины күргәннән соң тагын да тирәнрәк аңладым. Арпад кебек кешене минем үз гомеремдә күргәнем юк иде. Әтиебез өчен шундый дусты булу зур бәхет булган. Арпад турында документаль фильм төшерергә кирәк дип уйлыйм. Бу эш белән шөгыльләнә дә башлаячакмын, – дип сөйләде Мансур әфәнде.

Люция ХӘБИБУЛЛИНА.


## ОАО «Сетевая компания» готово к безопасному прохождению паводка

**Сетевая компания контролирует состояние 602 электросетевых объектов, которые расположены в зоне возможного подтопления.**

В условиях весеннего потепления и возможного осложнения паводковой ситуации сетевая компания реализует все необходимые мероприятия для обеспечения надежной безопасной работы электросетевого комплекса и устойчивого электроснабжения потребителей Республики Татарстан. Для этого во всех филиалах созданы паводковые комиссии и намечены к выполнению 352 профилактических мероприятия по защите энергообъектов от затопления. Противопаводковую комиссию ОАО «Сетевая компания» возглавляет заместитель генерального директора – технический директор Рашат Хамматович Галимзянов.

Своевременная подготовка к периоду паводка во всех филиалах позволяет компании проходить его в безаварийном режиме, надежно и качественно снабжая потребителей электроэнергией.

Проводятся периодические осмотры кабельных и воздушных линий электроснабжения, трансформаторных подстанций и ведется работа по защите опор линий электропередач, расположенных в пойменных участках; приведены в рабочее состояние дренажные устройства и средства водоотлива; проверено состояние сигнальных знаков и освещение переходных опор через судоходные реки. Обеспечен резерв необходимых материалов, инструмента, техники, оборудования и автотранспорта для оперативной ликвидации возможных повреждений и аварийных ситуаций. Для основной сети 35 кВ и выше определены места хранения аварийного запаса в Казанских и Чистопольских электрических сетях, для распределительной сети – во всех филиалах сетевой компании.

Ведется непрерывный мониторинг развития паводковой ситуации, чтобы не пропустить возникновения реальной угрозы для работы электросетевых объектов. На данный момент сформирован список из 433 объектов, угроза или подтопление которых наблюдались за последние 3 года в период прохождения паводка, и перечень объектов, находящихся в зонах повышенного риска в паводковый период 2017 года, в который вошли 602 объекта.

На случай чрезвычайных ситуаций, связанных с прохождением весеннего паводка, на предприятии находятся в готовности 94 оперативно-выездные бригады, в составе которых 188 человек личного состава, 195 единиц специальной техники, 11 плавательных средств.

Проведены дополнительные инструктажи и противоаварийные тренировки персонала по отработке действий в условиях паводка. Проверена готовность 33 передвижных дизель-генераторных установок, которые могут быть использованы в качестве резервного источника электроснабжения.

Реализация всех противопаводковых мероприятий осуществляется энергетиками в тесном взаимодействии с местными администрациями, Министерством по делам ГО и ЧС, гидрометеорологическими службами.

Слаженность и скоординированность общих действий позволяет добиваться положительного результата в работе, а именно обеспечения потребителей республики надежным электроснабжением вне зависимости от погодных условий.

**ВНИМАНИЕ!**
**Жителям, проживающим в зоне возможного подтопления, не рекомендуется приближаться к линиям электропередач и трансформаторным подстанциям ближе чем на 10 метров. Если вы заметили обрыв провода в таких зонах, звоните по круглосуточному бесплатному телефону контакт-центра ОАО «Сетевая компания»: 8-800-2000-878.**

## Чайнворд «Йорт»




**1.** Йортны тышкы һәм эчке яктан бизәп торучы нәкышләр.
**2.** Кеше килгәнне белдерү өчен, ишек яңагына беркетелгән махсус төймә.
**3.** Өстәл артына утыру җиһазы.
**4.** Фатир диварына эленгән рәсем.
**5.** Йорттагы телевизорның «мыегы».
**6.** Йортның йозагын ачып керү әсбабы.
**7.** Йорттагы чүпләрне түгү өчен савыт.
**8.** Йорт төзү өчен эш ...лары да кирәк.
**9.** Биек йортларда кешеләрне югарыга күтәрү җайланмасы.
**10.** Люстраларны ...гә элеп (асып) куялар.
**11.** Элегрәк йортларны ... ягып җылытканнар.
**12.** Йортка сыланып төзелгән ягылмый торган янкорма.
**13.** Агач йортның бурасын хуш исле ... бүрәнәләрдән бурыйлар.
**14.** Көн яктылыгы йортка ...лар аша төшә.

**Нияз Бишбалта** төзеде.

Җаваплар.
1.Бизәк 2.Кыңгырау 3.Урындык 4.Картина 5.Антенна 6.Ачкыч 7.Чиләк 8.Корал 9.Лифт 10.Түшәм 11.Мич
12.Чолан 13.Нарат 14.Тәрәзә.

## Как купить электронный полис ОСАГО?

**Не так давно у автолюбителей появилась удобная альтернатива бумажному полису ОСАГО – возможность оформить его через Интернет. С 1 января 2017 года все страховые компании, которые имеют лицензию на заключение договоров ОСАГО, обязаны заключать его в электронном виде на всей территории Российской Федерации. Купить полис можно на сайте страховой компании в интернете, не выходя из дома, при этом доступ к сайту страховой организации может осуществляться через сайт Российского союза автостраховщиков.**

Онлайн-продажи позволяют существенно повысить доступность услуги ОСАГО. Так, по данным Российского союза автостраховщиков (РСА), в Татарстане за январь текущего года приобретено 1533 полиса.

Стоимость как бумажного, так и электронного полиса ОСАГО рассчитывает одна и та же информационная система страховщика, поэтому нет разницы, приобретается он в офисе, у агента или через Интернет. Для расчета стоимости полиса можно воспользоваться калькулятором ОСАГО, размещенным на официальном сайте Российского союза автостраховщиков www.autoins.ru в разделе «ОСАГО / Расчет стоимости ОСАГО».

Перед заключением договора стоит проверить, доступна ли база Российского союза автостраховщиков (а именно к ней обращается страховщик при заключении договора), это может сделать сам автовладелец. Для этого РСА ввел систему «светофор» (если «зеленый», то база доступна). Проверить доступность онлайн-ресурсов с использованием «светофора» можно по ссылке: **http://dkbm-web.autoins.ru/dkbmweb-1.0/kbm_to_availability.htm.**

При покупке электронного полиса важно аккуратно заполнять поля на сайте страховщика. Электронное ОСАГО для большинства потребителей является новым сервисом, автовладельцы только привыкают к возможности общаться со страховщиком по Интернету.

Процедура покупки электронного полиса достаточно простая, для нее потребуются те же самые документы, что и для приобретения полиса в офисе, – паспорт, водительское удостоверение, документы о регистрации транспортного средства и диагностическая карта (для автомобилей старше трех лет).

В случае невозможности оформления полиса е-ОСАГО, необходимо понять, с какой именно проблемой столкнулся автолюбитель и на каком этапе.

Например, если сайт страховщика выдает ошибку на этапе регистрации или авторизации на сайте, либо не поступают логин и пароль, автолюбителям просто нужно повторить процедуру через некоторое время. Иногда трафик в рабочее время достаточно высок, и сайты страховщиков могут не справляться с возросшим числом заявок на оформление полиса е-ОСАГО. Можно попробовать воспользоваться их сервисами в нерабочее время или в выходной день.

Также следует обратить внимание на качество интернет-соединения. Если проблема в нём, то обратиться к интернет-провайдеру.

Если проблема не с соединением, но сайт страховой компании выдает ошибку, необходимо попробовать обратиться в call-центр страховщика.

В случае если предыдущие варианты уже были опробованы и это не принесло результата, вы можете подать жалобу в письменном виде в Отделение – Национальный банк по Республике Татарстан Волго-Вятского главного управления Банка России по адресу: 420013, г. Казань, ул. Баумана, д. 37. Также можно заполнить электронную форму в интернет-приемной Банка России: **www.cbr.ru.**

К обращению нужно приложить скриншот экрана мобильного устройства или персонального компьютера с фиксацией даты и времени обращения к сайту страховой компании. Без скриншота невозможно установить, что действительно доступа к электронному полису не было. Если у вас уже имеется доступ к личному кабинету страхователя ОСАГО нужно указать в обращении также логин. Указание таких параметров как IP-адрес, MAC-адрес и номер SIM-карты позволит в ряде случаев более детально разобраться в возникших сложностях.

## Внимание: нефтепровод!

**Альметьевское районное нефтепроводное управление доводит до сведения всех руководителей, совхозов и колхозов, всех жителей городов и районов, что на территории Альметьевского, Бугульминского, Лениногорского, Новошешминского, Чистопольского, Алексеевского, Тукаевского, Заинского, Сармановского, Актанышского, Мензелинского, Муслюмовского, Азнакаевского, Ютазинского и Нижнекамского районов проходят магистральные нефтепроводы большого диаметра, обозначенные специальными опознавательными знаками.**

В целях обеспечения сохранности магистральных нефтепроводов, создания нормальных условий их эксплуатации и предотвращения несчастных случаев «Правилами охраны магистральных трубопроводов», Постановлением № 367 Кабинета министров Республики Татарстан «О мерах по обеспечению безопасной эксплуатации и повышению надежности работы магистральных нефтепроводов по транспортированию углеводородного сырья и баз их хранения» и другими руководящими документами установлена охранная зона вдоль трассы трубопроводов шириной 25 метров в каждую сторону от оси крайних нефтепроводов. В охранной зоне магистральных нефтепроводов без письменного разрешения и согласования с Альметьевским районным нефтепроводным управлением.

**ЗАПРЕЩАЕТСЯ:**

- Возводить любые постройки и сооружения, производить всякого рода горные, карьерные, строительные, монтажные и взрывные работы.
- Выполнять земляные и мелиорационные работы.
- Располагать полевые станы, загоны для скота, складировать корма, удобрения, материалы, скирдовать солому и сено, сажать деревья и кустарники, размещать культурные, коллективные сады и огороды.
- Устраивать стрельбища и размещать свалки.
- Перемещать, сносить и производить засыпку грунтом, переставлять и повреждать опознавательные, запрещающие и другие знаки и контрольно-измерительные колонки.
- Открывать крышки, люки, калитки, двери и замки колодцев, ограждений узлов линейной арматуры, блок-боксов, установок катодной защиты.
- Разводить огонь и размещать любые закрытые и открытые источники огня.

В охранной зоне запрещается проводить любые мероприятия, связанные со скоплением людей, не занятых выполнением разрешенных в установленном порядке работ.

Полевые сельскохозяйственные работы в охранной зоне нефтепроводов производятся землепользователем после предварительного уведомления предприятия, эксплуатирующего трубопроводы.

Проезд автотракторной техники через нефтепровод допускается только по специально оборудованным переездам и дорогам общего пользования с твердым покрытием.

**ВСЕ РАБОТЫ В ОХРАННОЙ ЗОНЕ НЕФТЕПРОВОДА ПРОИЗВОДЯТСЯ ТОЛЬКО В ПРИСУТСТВИИ ПРЕДСТАВИТЕЛЯ НПС.**

**К лицам, виновным в нарушении Правил охраны магистральных трубопроводов, если эти действия по своему характеру не влекут уголовной ответственности, могут быть применены в качестве меры административного взыскания предупреждение или штраф в соответствии со статьей 11.20.1 Кодекса об административных правонарушениях.**

Статья 11.20.1. Нарушение запретов либо несоблюдение порядка выполнения работ в охранных зонах магистральных трубопроводов (введена Федеральным законом от 12.03.2014 №31-ФЗ).

Совершение в охранных зонах магистральных трубопроводов действий, запрещенных законодательством Российской Федерации либо выполнение в охранных зонах магистральных трубопроводов работ без соответствующего разрешения предприятия трубопроводного транспорта или без его уведомления, влечет наложение административного штрафа на граждан в размере от пятидесяти тысяч до ста тысяч рублей; на должностных лиц – от пятисот тысяч до восьмисот тысяч рублей; на лиц, осуществляющих предпринимательскую деятельность без образования юридического лица, – от пятисот тысяч до восьмисот тысяч рублей или административное приостановление деятельности на срок до девяноста суток; на юридических лиц – от пятисот тысяч до двух миллионов пятисот тысяч рублей или административное приостановление деятельности на срок до девяноста суток.

Перед выполнением работ в охранной зоне нефтепроводов необходимо получить технические условия АО «Транснефть – Прикамье» по адресу: 440043, Республика Татарстан, Казань, ул. Н. Ершова, 26а. Телефоны: **(843) 279-02-90, 279-02-78, 279-04-34;** факс **(843) 279-01-12, 279-04-12.**

В случае обнаружения утечек (выходов) нефти необходимо немедленно сообщить по адресу: 423400 Республика Татарстан, Альметьевск, пр. Строителей, 24; тел. **(8553) 39-62-24; 39-62-32** (диспетчер РДП АРНУ), **39-61-55** (отдел эксплуатации АРНУ).

На правах рекламы

www.shahrikazan.com
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
twitter.com/shahri_kazan
ok.ru/shrikazan
instagram.com/shahrikazan



КАЗАНСКИЙ ЗАВОД СИЛИКАТНЫХ СТЕНОВЫХ МАТЕРИАЛОВ
КИРПИЧ от 8,24 р./шт.
5-707-909
5-719-259
www.kzssm.ru
ГАЗОБЕТОН от 50,40 р./шт.
ЖБИ изделия
ОТГРУЗКА КРУГЛОСУТОЧНО
Реклама

Реклама
**Требуются водители кат. C, D, E, автослесари. Вахтовый метод, зарплата сдельная.**
Тел.: 8-937-581-22-01, 8-906-117-15-12 (водители), 8-917-918-10-98 (слесари), (8552) 46-67-18.

# АФИША
## 6 – 12 МАРТ

### Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ
(ТАТАРСТАН УРАМЫ, 1)

**6 март** «Галиябану» (М. Фәйзи)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**8 март** «Хафалы биюләр» (С.Юзеев)
**Башлана:** 12.00
**Билет бәясе:** 300-350 сум
**8 март** «Бармы ришвәттән дәва?..» (З.Хәким)
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**9 март** «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**10 март** «Дон Жуан» (Ж.Б. Мольер)
**Башлана:** 19.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**11 март** «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш)
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум
**12 март** «Кечтүкле уен» (И.Зәйниев)
**Башлана:** 12.00
**Билет бәясе:** 120-500 сум
**12 март** «Бабайлар чуагы» (И.Зәйниев)
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 250-1500 сум

### К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ
(ГОРЬКИЙ УРАМЫ, 13)

**8 март** «Бәйрәм белән, кызлар!» (Ш.Фәрхетдинов, Р.Зәһидуллин)
**Башлана:** 17.00
**10 март** «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев)
**Башлана:** 18.30
**11 март** «Кияүләр» (К.Тинчурин )
**Башлана:** 17.00
**12 март** «Беренче мәхәббәт» (И.Гали)
**Башлана:** 17.00
**Билет бәясе:** 250-600 сум

### «ӘКИЯТ» КУРЧАК ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

**8 март** «Идет Коза рогатая» (М.Протасова)
**Башлана:** 10.00, 11.30
**8 март** «Өч кыз» (Г.Хаиров)
**Башлана:** 15.00
**8 март** «Ханума» (олылар өчен спектакль)
**Башлана:** 18.00
**10 март** «Волшебник изумрудного города» (А.Волков)
**Башлана:** 11.00, 13.00
**11 март** «Солнышко и снежные человечки» (А.Веселов)
**Башлана:** 11.00, 13.00
**11 март** «Котбетдин маҗаралары»
**Башлана:** 11.00
**12 март** «Цветик-семицветик» (В.Катаев, инсц.Б.Вайнера)
**Башлана:** 11.00, 13.00
**Билет бәясе:** 250-600 сум

### Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ
(ПЕТЕРБУРГ УРАМЫ, 57)

**9 март** «Галиябану» (М.Фәйзи)
**Башлана:** 18.30
**10 март** «Ширбәт ае» (А.Попов, Х.Ибраһим)
**Башлана:** 18.30
**Билет бәясе:** 150-200 сум

### Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ
(ПАВЛЮХИН УРАМЫ, 73)

**7 март** Артур-Марат дуэты концерты
**Башлана:** 18.30
**Билет бәясе:** 300-700 сум
**8 март** Рифат Зарипов
**Башлана:** 17.00
**Билет бәясе:** 500-1200 сум
**8 март** Рифат Зарипов
**Башлана:** 18.30
**Билет бәясе:** 500-1200 сум
**12 март** Филүс Каһиров
**Башлана:** 17.00
**Билет бәясе:** 400-1200 сум

### УНИКС
(ПРОФЕССОР НУЖИН УРАМЫ 2/27)

**8 март** Фирдүс Тямаев концерты
**Башлана:** 17.00

### «ПИРАМИДА» МӘДӘНИ-КҮҢЕЛ АЧУ ҮЗӘГЕ
(МӘСКӘҮ УРАМЫ, 3)

**11 март** Валерий Меладзе концерты
**Башлана:** 18.00
**Билет бәясе:** 2500 сум

### «ШӘҺРИ КАЗАН» РЕДАКЦИЯСЕНЕҢ КҮРГӘЗМӘЛӘР ЗАЛЫ
(ЧИСТАЙ УРАМЫ, 5)

«Күчеп йөрүче ХӘБӘР» – Халыкара сәнгать проекты күргәзмәсе. Проект авторлары Әлфия Ильясова (Татарстан) һәм Наталья Николаева (Саха-Якутия).
**Керү ирекле** (эш көннәрендә)

5+



deviantart.com

# Бер ягында аның...

**Без кечкенә чакта совет иле турында «Бер ягында аның кояш чыга» дип башланган җыр бар иде. Илнең зурлыгын, бөеклеген шулай җыр аша да сеңдерәләр иде.**

Февральнең 21е көнне Казанда яңгыр явып торды. Башкаладан 300 чакрым көнчыгыштагы туган авылыма, газиз әниемә шалтыраттым. «Бездә кояш, карлар эри», – диде ул, күңелле генә. Берәздән Башкортстанның Әлшәй районыннан якын бер кешем шалтыратты: «Стәрлетамакка дип юлга чыккан идек, буран машинаны күтәрә, белмим, ничек барып җитәрбез», – дип, күңелгә шөбһә салды. Ярмәкәйгә Флюра Низамовага шалтыраттым. «Ишегалдында кар таптап йөрим, күрәп бетерерлек түгел», – диде ул, күр тавыш белән. Уфалылар да, екатеринбурглылар да үзләрендә һава торышының тыныч булуын хәбәр итте. Телефоннан сөйләшеп туйгач, татар халкы турында уйланып утырдым. Эх, совет иле кадәр үк булмаса да, татарымызның ҮЗ җирләре зур, бик зур шул. Ә иң мөһиме, татар бүген дә шул җирләрендә көн күреп, үз телендә сөйләшеп яши. Татар җирләренең бер очында – буран, икенчесендә – кояш, өченчесендә – яңгыр... Рәхәт бит, шайтан алгыры!

**Илфак ШИҺАПОВ.**

## ТАШКА БАСКАН

✓ Кул кулны юа, аяк аякны кашый, ә колаклар белән проблема.

✓ Башта үзеңә хуҗа бул, аннан соң башкалар турында уйларсың.

✓ Зирәкләр сорау куя, акыллылар җавап таба, ахмаклар карар кабул итә.

✓ Бер дәлилсез исбатлау «җәмәгатьчелек фикере» дип атала.

✓ Тормыш юлдашын күз белән генә түгел, колак белән дә сайларга кирәк.

✓ Тел сөйли, ә баш җавап тота.

✓ Бөркет оча алмаган җирдә чебен оча ала.

✓ Тулып җитмәгән чиләктә су ныграк чайпала.

✓ Яшьлегеңдә ни чәчсәң, картлыгыңда шуны урырсың.

✓ Акчаны саклык белән тоту аны табудан авыррак.

✓ Кыйммәтле киңәш – алтыннан кадерлерәк.

✓ Киңәшкә колак салмаганның колагын борудан файда юк.

✓ Миллионлаган ир-егетнең ялгышуы мөмкин түгел: хәмер – файдалы.

✓ Бер генә чит ил теле дә миңа хуҗа була алмады.

✓ Әгәр тормыш сине роза таҗларына күмә икән, башыңны күтәреп кара: өстән гөл чүлмәге очмыймы икән.

✓ Сөйләргә оят, искә алырга рәхәт мизгелләр булса, бу яшәү дип атала.

✓ Әгәр намусың борчымаслык итеп яшәргә тырышсаң, ул ачтан үләчәк.

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 66 сум 99 тиен
3 айга 200 сум 97 тиен
6 айга 401 сум 94 тиен
Реклама

Ташламалы бәядән язылып кал!
һәр айның 15 числосына кадәр язылсагыз, газета киләсе ай башыннан киләчәк.
Синең өчен, синең турында!

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)
136 сум 15 тиен 1 айга
408 сум 45 тиен 3 айга
816 сум 90 тиен 6 айга


ВРЕМЯ ЗАКАЗЫВАТЬ ТЕПЛИЦЫ ОТ ЗАВОДА
8(843) 240-95-10
8(962) 556-38-22
ГАРАНТИЯ КАЧЕСТВА И НИЗКОЙ ЦЕНЫ
Реклама

Шәһри КАЗАН

ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ – БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562-50-12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843). 562-50-03,
E-mail: shahri-kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Бу санның тиражы – 1668. Гомуми тираж – 6338.
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 683. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор). 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77-50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан, Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843). 562-50-12, факс: (843). 562-50-07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы